МИНИСТЕРСТВО ТРАНСПОРТА
И ДОРОЖНОГО ХОЗЯЙСТВА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТРАНСПОРТ ҺӘМ ЮЛ
ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

**БОЕРЫК** **ПРИКАЗ**

**от «18» июля 2017** **№ 241_**

Боерык

Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының 2014 елның 07 июлендәге №214 Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өлкәсендә төбәк дәүләт контролен гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен башкаруның административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Б о е р ы к б и р э м:

Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өлкәсендә төбәк дәүләт контролен гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен башкаруның Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының 2014 елның 7 июлендәге 214 номерлы приказы (Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының 2014 елның 12 ноябрендәге 376 номерлы боерыгы белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган административ регламентына, аны яңа редакциядә бәян итеп, түбәндәге үзгәрешләрне кертергә (кушымта итеп бирелә).

Министр Л.Р. Сафин

Татарстан Республикасы
Транспорт һәм юл хуҗалыгы
министрлыгының
2014 елның 7 июлендәге
№214 боерыгы белән
расланды
(Татарстан Республикасы
Транспорт һәм юл хуҗалыгы
министрлыгының
2017 елның 18 июлендәге
№241 боерыгы редакциясендә)

**Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өлкәсендә төбәк дәүләт контролен гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен башкаруның административ регламентына**

## 1. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

### ДӘҮЛӘТ ФУНКЦИЯСЕ ИСЕМЕ

1.1. Әлеге Регламент Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының (алга таба – Министрлык) “җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өлкәсендә төбәк дәүләт контролен гамәлгә ашыру” буенча дәүләт функциясен (алга таба – дәүләт функциясе, региональ дәүләт контроле) үтәү таләпләрен, срокларын һәм тәртибен билгели.

### ДӘҮЛӘТ ФУНКЦИЯСЕН ҮТИ ТОРГАН ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ ХАКИМИЯТЕ БАШКАРМА ОРГАНЫ ИСЕМЕ

1.2. Дәүләт вазыйфасын үтәүче Татарстан Республикасы башкарма хакимият органы булып Министрлык тора.

Дәүләт вазыйфасын турыдан-туры үтәүче булып Министрлыкның Транспорт идарәсе автомобиль транспорты бүлеге (алга таба – Бүлек, Идарә) тора.

Дәүләт вазыйфасы Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министры (алга таба – министр), Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министры урынбасары (алга таба – министр урынбасары) боерыгы белән тикшерү үткәрүгә вәкаләт бирелгән Министрлыкның вазыйфаи затлары (алга таба – вазыйфаи затлар) тарафыннан турыдан-туры башкарыла.

“Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында” 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль законның 13.3 статьясы һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Тикшерүләрнең бердәм реестрын булдыру һәм алып бару кагыйдәләре турында” 2015 елның 28 апрелендәге 415 номерлы карары нигезендә тикшерүләрнең бердәм реестрына тиешле мәгълүмат кертү Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи заты тарафыннан башкарыла.

Дәүләт вазыйфасын үтәгәндә вазыйфаи затлар прокуратура органнары, экспертлар оешмалары, дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, юридик затлар һәм индивидуаль эшкуарлар белән хезмәттәшлек итә.

## ДӘҮЛӘТ ФУНКЦИЯСЕН ҮТӘҮНЕ ТӘРТИПКӘ САЛУЧЫ НОРМАТИВ ХОКУКЫЙ АКТЛАР ИСЕМЛЕГЕ

1.3. Министрлык тарафыннан дәүләт функциясен үтәү түбәндәгеләр нигезендә гамәлгә ашырыла:

Россия Федерациясе Конституциясе (“Российская газета”, 1993 елның 25 декабре, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексы (алга таба – РФ КоАП) (Россия Федерациясе законнар җыелмасы, 2002 ел, № 7, 1 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында” 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 294-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнар җыелмасы, 2008 ел, № 52, 6249 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында” 2011 елның 21 апрелендәге 69-ФЗ номерлы Федераль законы (алга таба – 69-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнар җыелмасы, 2011 ел, № 17, 2310 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карап тикшерү тәртибе турында” 2006 елның 2 маендагы №59-ФЗ Федераль закон (алга таба – №59-ФЗ Федераль закон) (“Россия Федерациясе законнар җыелмасы, 2006 ел, №19, 2060 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Пассажирларны һәм багажны автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында ташу кагыйдәләрен раслау турында” (алга таба – Кагыйдәләр) 2009 елның 14 февралендәге 112 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары (Россия Федерациясе законнар җыелмасы, 2009 ел, №9, 1102 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Дәүләт контрольлеге (күзәтчелек) һәм муниципаль контрольле органнары тарафыннан юридик затларга һәм индивидуаль эшкуарларга планлы тикшерүләр

үткәрүнең еллык планнарын әзерләү кагыйдәләрен раслау турында" 2010 елның 30 июнендәге 489 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары (Россия Федерациясе законнар җыелмасы, 2010 ел, №28, 3706 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

"Тикшерүләрнең бердәм реестрын булдыру һәм алып бару кагыйдәләре турында" Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2015 елның 28 апрелендәге 415 номерлы карары (алга таба – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 415 номерлы карары) (Россия Федерациясе законнар җыелмасы, 2015 ел, № 19, 2825 ст.);

"Мәҗбүри таләпләрне бозуның рөхсәт ителмәве турында кисәтү, юридик зат, индивидуаль эшкуар тарафыннан мондый кисәтүләргә ризасызлык белдерү һәм аларны карау, мондый кисәтүләрне үтәү турында хәбәрнамә төзү һәм җибәрү кагыйдәләрен раслау хакында" Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 10 февралендәге 166 номерлы карары (алга таба – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 166 номерлы карары) (Россия Федерациясе законнар җыелмасы, 2017 ел, № 8, 1239 ст.);

"Дәүләт контрольлеген (күзәтчелек) һәм муниципаль контрольлекне хәл иткәндә юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын саклау турында" Федераль закон нигезләмәләрен тормышка ашыру хакында" 2009 елның 30 апрелендәге №141 номерлы Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы боерыгы (алга таба – №141 Россия икътисадый үсеш министрлыгы боерыгы) ("Российская газета", 14 май, 2009 ел, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

"Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксида пассажирлар һәм багаж ташу турында" 2011 елның 10 октябрендәге 77-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы (алга таба – 77-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы) (Республика Татарстан Дәүләт Советының җыелма басмасы 2011 ел, №10, 1219 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

"Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы мәсьәләләре" турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 елның 6 июлендәге 317 номерлы карары ("Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары, боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнарының норматив актлары җыентыгы", 2005 елның 27 июле, № 28, 0646 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

"Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксида пассажирлар һәм багаж ташу турында" 2011 елның 10 октябрендәге 77-ТРЗномерлы Татарстан Республикасы Законын тормышка ашыру чаралары хакында" 2011 елның 6 декабрендәге 999 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары ("Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары, боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнарының норматив актлары җыентыгы", 2012 елның 13 гыйнвары, №3, 0077 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

"Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгыныңТатарстан Республикасы территориясендә җиңел таксида пассажирлар һәм багаж ташу өлкәсендә административ хокук бозулар турында" беркетмәләр төзүгә һәм эшләрне карап тикшерүгә вәкаләтле вазыйфаи затлары исемлеген раслау турында" 2012 елның 13 сентябрендәге 156 номерлы Татарстан

Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы боерыгы (алга таба – 156 номерлы Министрлык боерыгы) (“Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары, боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнарының норматив актлары җыентыгы”, 2012 елның 19 октябре, №78, 2609 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып).

## РЕГИОНАЛЬ ДӘҮЛӘТ КОНТРОЛЕ ПРЕДМЕТЫ

1.4 Төбәк дәүләт контрольлеге предметы булып Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксида пассажирлар һәм багаж ташу эшчәнлеген хәл итүче юридик хатларныңһәм индивидуаль эшкуарларның(алга таба – юридик затлар, индивидуаль эшкуарлар) эшчәнлекнеңәлеге төрен хәл итүгә Министрлык тарафыннан бирелгән рөхсәтләрнең, бу Регламентның3 бүлегендә бәян ителгән мәҗбүри таләпләрне үтәвенә төбәк дәүләт контрольлеге (турыдан-туры җиңел таксида пассажирлар һәм багаж ташу процессында әлеге таләпләрне үтәүгә контрольлектән тыш) (алга таба – мәҗбүри таләпләр) тора.

## РЕГИОНАЛЬ ДӘҮЛӘТ КОНТРОЛЕ ОБЪЕКТЛАРЫ

Төбәк дәүләт контрольлеге объекты булып Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксида пассажирлар һәм багаж ташу буенча юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның эшчәнлеге тора (алга таба - контроль объектлары; юридик затлар һәм индивидуаль эшкуарлар).

## РЕГИОНАЛЬ ДӘҮЛӘТ КОНТРОЛЕН БАШКАРГАНДА МИНИСТРЛЫК ВАЗЫЙФАИ ЗАТЛАРЫНЫҢ ХОКУКЛАРЫ ҺӘМ БУРЫЧЛАРЫ

1.6. Тикшерү үткәрүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар тикшерү үткәргәндә хокуклы:

1) мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен тикшерү, әгәрдә андый таләпләр Министрлык вәкаләтләренә караса;

2) хезмәт таныклыгын һәм тикшерү үткәрү турында министр (министр урынбасары) боерыгын күрсәтеп, юридик зат, индивидуаль эшкуар тарафыннан үз эшчәнлеген хәл итүдә файдаланыла торган территорияләрдә, бина, корылма, бүлмә, җиһаз, транспорт чарасында булу һәм карау;

3) тикшерү үткәрү турында боерык чыгарылганнан соң контроль объектыннан кирәкле документларны һәм (яисә) мәгълүматны соратып алу, документларны тикшерү барышында белешмәләрнең дөрес түгеллеге ачыкланган очракта, контроль объекты адресына дәлилләнгән гарызнамәләр җибәрү, урынга барып тикшерү үткәрелгәндә, моңа кадәр документлар буенча тикшерү үткәрелмәгән булса, контроль объектыннан контроль предметының максатлары, бурычлары һәм предметы белән бәйле документлар алу;

6) юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга күчмә тикшерү үткәрүгә үзләренә

карата тикшерү үткәрелә торган юридик затлар, индивидуаль эшкуарлар белән гражданлык-хокукый һәм хезмәт мөнәсәбәтләрендә тормаган һәм тикшерелә торган затларныңаффилирланган затлары булып тормаган экспертлар, эксперт оешмалары җәлеп итү;

7) юридик затлардан, индивидуаль эшкуарлардан законныңмәҗбүри таләпләрен бозу факты буенча аңлатмалар алу.

1.7. Тикшерү үткәрүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар тикшерү үткәрүдә бурычлы:

1) мәҗбүри таләпләрне бозуны кисәтү, ачыклау һәм бозуларга киртә кую вәкаләтләрен Россия Федерациясе законы нигезендә үз вакытында һәм тулы күләмендә үтәү;

2) Россия Федерациясе законнарын һәм Татарстан Республикасы законнарын, үзләренә карата тикшерү үткәрелә торган юридик зат, индивидуаль эшкуар хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү;

3) тикшерүне тикшерү үткәрү турында министр (министр урынбасары) боерыгын билгеләнеше нигезендә үткәрү;

4) тикшерүне фәкать хезмәт бурычларын үтәү вакытында гына үткәрү, күчмә тикшерүне фәкать хезмәт таныклыкларын, министр (министр урынбасары) боерыгы күчермәсен күрсәткәч кенә үткәрү һәм законда күздә тотылган очракта, тикшерелә торган затларның эшчәнлеген хәл итү урыны буенча прокуратура органы белән тикшерү үткәрүне килештерү турында документ күчермәсен күрсәткәч үткәрү;

5) юридик зат җитәкчесенә, башка вазыйфаи затына яки вәкаләтле вәкиленә, индивидуаль эшкуаргә, аныңвәкаләтле вәкиленә тикшерү үткәрүне карап торуга һәм тикшерү предметына керүче мәсьәләләр буенча аңлатмалар бирүгә комачауламау;

6) тикшерү үткәрүне карап торган юридик зат җитәкчесенә, башка вазыйфаи затына яки вәкаләтле вәкиленә, индивидуаль эшкуаргә, аныңвәкаләтле вәкиленә тикшерү предметына керүче мәгълүмат һәм документлар тапшыру;

7) юридик зат җитәкчесен, башка вазыйфаи затын яки вәкаләтле вәкилен, индивидуаль эшкуарне, аныңвәкаләтле вәкилен тикшерү нәтиҗәләре белән таныштыру;

8) юридик зат җитәкчесен, башка вазыйфаи затын яисә вәкаләтле вәкилен, индивидуаль эшкуарны, аның вәкаләтле вәкилен ведомствоара мәгълүмат алмашу кысаларында алынган документлар һәм (яисә) мәгълүмат белән таныштыру

9) ачыкланган бозу фактлары буенча күрелә торган чараларны билгеләгәндә әлеге чараларныңбозу дәрәҗәсенә туры килүен, аларныңкешеләр тормышы, сәламәтлеге өчен, хайваннар, үсемлекләр, әйләнә-тирә мохит, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкәрләр) өчен, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрнеңкилеп чыгуы өчен куркыныч тудыру ихтималын исәпкә алу, шулай ук гражданнарның, шул исәптән индивидуаль эшкуарларның, юридик затларның хокукларын һәм законнарын нигезсез чикләүгә юл куймау

10) үзләренеңгамәлләренә юридик затлар, индивидуаль эшкуарлар тарафыннан Россия Федерациясе законында билгеләнгән тәртиптә шикаять белдерелгәндә, үз

гамәлләренеңнигезлегеn дәлилләү;

11) 294-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тикшерү үткәрү срокларын үтәү;

12) юридик заттан, индивидуаль эшкуардән Россия Федерациясе законында күздә тотылмаган документлар һәм башка мәгълүматлар тапшыруны таләп итмәү;

13) юридик зат җитәкчесе, башка вазыйфаи заты яки вәкаләтле вәкиле, индивидуаль эшкуар, аныңвәкаләтле вәкиле үтенче белән күчмә тикшерү үткәрү башланганчы, аларны бу Регламент нигезләмәләре белән таныштыру;

14) юридик затта, индивидуаль эшкуарда тикшерүләрне исәпкә алу журналы булган очракта, үткәрелгән тикшерү турында әлеге журналга язып кую;

15) ачыкланган хокук бозулар фактларына карата Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән чаралар күрү.

Тикшерү барышында вазыйфаи затлар Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән исемлеккә кертелгән документларны һәм (яисә) мәгълүматны бу документлар һәм (яисә) мәгълүмат саклана торган дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан йә дәүләт органнарына яисә җирле үзидарә органнарына караган оешмалардан түләүсез нигездә ведомствоара мәгълүмат алмашу кысаларында Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән срокларда һәм тәртиптә соратып алалар.

План буенча 2016 елның 1 гыйнварыннан 2018 елның 31 декабренә кадәр күчмә тикшерү үткәрелү чорында җитәкчегә, башка вазыйфаи затка яки юридик затның вәкаләтле вәкиленә, индивидуаль эшкуарга, аның вәкаләтле вәкиленә 294-ФЗ номерлы Федераль закон 26.1 статьясының 1, 2, 5 өлешләре аңлатыла.

1.8. Тикшерү үткәрергә вәкаләтле вазыйфаи затларга тикшерү үткәргәндә түбәндәгеләр тыела:

1) мәҗбүри таләпләр бу вазыйфаи затлар эш итә торган Министрлык вәкаләтләренә кермәгән очракта, мондый таләпләрнең үтәлешен тикшерү;

2) СССР һәм РСФСР башкарма хакимияте органнарының норматив хокукый актлары белән билгеләнгән таләпләрнең үтәлешен тикшерү, шулай ук Россия Федерациясе законнарында мәҗбүри куллану каралмаган норматив документлар таләпләренең үтәлешен тикшерү;

3) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә басылып чыкмаган хокукый актларда билгеләнгән мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен тикшерү;

4) юридик зат җитәкчесе, башка вазыйфаи заты яисә вәкаләтле вәкиле, индивидуаль эшкуар булмаганда урынга барып планлаштырылган йә планлаштырылмаган тикшерү үткәрү, моңа әлеге Регламентның 1 нче таблицасындагы 3.1 – 3.3 пунктларында күрсәтелгән таләпләр бозылу (әгәр бу таләпләрне бозу кешеләр гомеренә һәм сәламәтлегенә, әйләнә-тирә мохиткә, физик һәм юридик затлар мөлкәтенә янаса, техноген характердагы аварияләр һәм (яисә) гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу куркынычы тудырса йә мондый зарар килүгә, техноген характердагы аварияләр һәм (яисә) гадәттән тыш хәлләр килеп чыгуга сәбәпче булса) нигезендә үткәрелгән тикшерүләр керми;

5) әйләнә-тирә мохит объектлары һәм җитештерү мохите объектлары тикшерү объекты булып тормаса һәм тикшерү предметына карамаса, аларны өйрәнү документларын, мәгълүматын, продукция өлгеләрен һәм алынган пробаларны тапшыруны таләп итү, шулай ук мондый документларның оригиналларын алып китү;

6) продукция өлгеләрен, әйләнә-тирә мохит объектларын һәм җитештерү мохите объектларын өйрәнү пробаларын алып китү турында беркетмәләр төземичә генә бу өлгеләрне, пробаларны билгеләнгән рәвештә һәм илкүләм стандартларда, өлгеләрне, пробаларны алып китү кагыйдәләрендә һәм аларны тикшерү, сынау, үлчәү ысулларында, техник регламентларда яисә алар гамәлгә кергәнче гамәлдә булган башка норматив техник документларда һәм тикшерү, сынау, үлчәү ысулларында билгеләнгән нормалардан артыграк күләмдә тикшерү, сынау, үлчәү өчен алып китү;

7) тикшерү нәтиҗәсендә билгеле булган һәм дәүләт, коммерция, хезмәт, законнар белән саклanучы башка серне тәшкил итә торган мәгълүматны Россия Федерациясе законнарында каралган очраклардан тыш тарату;

8) тикшерү үткәрүнең билгеләнгән срокларын арттыру;

9) юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга контроль чараларын алар хисабына үткәрү турында күрсәтмәләр яисә тәкъдимнәр бирү;

10) юридик заттан, индивидуаль эшкуардан Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән исемлеккә кертелгән документларны һәм (яисә) мәгълүматны таләп итү, моңа башка дәүләт органнарында, җирле үзидарә органнарында яисә дәүләт органнарына йә җирле үзидарә органнарына караган оешмаларда булган рөхсәт бирү документлары да керә;

11) тикшерү башлану датасына кадәр юридик заттан, индивидуаль эшкуардан документлар, мәгълүмат таләп итү. Тикшерү үткәрү турында боерык чыгарылганнан соң Министрлык кирәкле документларны һәм (яисә) мәгълүматны) ведомствоара мәгълүмат алмашу кысаларында соратып алу хокукына ия.

## ҮЗЛӘРЕНӘ КАРАТА КОНТРОЛЬ ЧАРАЛАРЫ ГАМӘЛГӘ АШЫРЫЛА ТОРГАН ЗАТЛАРНЫҢ ХОКУКЛАРЫ ҺӘМ БУРЫЧЛАРЫ

1.9. Юридик зат җитәкчесе, башка вазыйфаи заты яки вәкаләтле вәкиле, индивидуаль эшкуар, аның вәкаләтле вәкиле тикшерү үткәрелгәндә хокуклы:

1) тикшерү үткәрелгәндә турыдан-туры катнашу, тикшерү предметына керүче мәсьәләләр буенча аңлатмалар бирү;

2) Министрлыктан, Министрлыкның вазыйфаи затларыннан тикшерү предметына керә торган, 294-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә тапшырылырга тиешле мәгълүмат алу;

3) башка дәүләт органнарында, җирле үзидарә органнарында йә дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына караган оешмаларда булган, ведомствоара мәгълүмат алмашу кысаларында Министрлык соратып алган документлар һәм (яисә) мәгълүмат белән танышырга;

4) ведомствоара мәгълүмат алмашу кысаларында соратып алына торган

документларны һәм (яисә) мәгълүматны үз теләге белән Министрлыкка тапшырырга;

5) тикшерү нәтиҗәләре белән танышу һәм тикшерү актына тикшерү нәтиҗәләре белән танышуы, алар белән килешүе яки килешмәве, шулай ук Министрлыкның вазыйфаи затларының аерым гамәлләре белән килешүе яки килешмәве турында күрсәтү;

6) тикшерү үткәрүдә юридик затның, индивидуаль эшкуарның хокукларын бозуга китергән Министрлыкның вазыйфаи затлары гамәлләренә (гамәл кылмау) Россия Федерациясе законы нигезендә административ һәм (яки) суд тәртибендә шикаять белдерү;

7) Россия Федерациясе Президенты каршында эшкуарларның хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилне яки Татарстан Республикасы Президенты каршында эшкуарларның хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилне тикшерүдә катнашуга җәлеп итәргә.

1.10. Юридик затлар, индивидуаль эшкуарлар Россия Федерациясе законы нигезендә билгеләнгән тәртиптә, хокукка каршы килә дип танылган Министрлыкның вазыйфаи затлары гамәлләре (гамәл кылмау) аркасында күзәтчелек чараларын хәл итү вакытында китерелгән зыянны каплауга хокуклы.

1.11. Тикшерү үткәрелгәндә индивидуаль эшкуарлар, юридик затлар бурычлы:

1) тикшерү предметына керүче мәсьәләләр буенча тикшерү үткәрүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар тарафыннан соралган документлар һәм материаллар бирү;

2) тикшерү үткәрүгә вәкаләтле вазыйфаи затларныңэшчәнлек алып бару процессында файдаланыла торган территориягә, бина, корылма, бүлмә, җиһаз, транспорт чараларына комачаулыксыз керүен тәэмин итү.

## ДӘҮЛӘТ ФУНКЦИЯСЕН БАШКАРУ НӘТИҖӘЛӘРЕ

1.12. Дәүләт вазыйфасын башкару нәтиҗәләре булып җиңел таксида пассажирлар һәм багаж ташу эшчәнлеген хәл итүдә мәҗбүри таләпләрне бозуларны кисәтү, ачыклау һәм аларга киртә кую тора.

Дәүләт функциясен башкаруның ахыргы нәтиҗәләре булып тора:

юридик затны, индивидуаль эшкуарне тикшерү (тикшерү үткәрү турында актның формасы 141 номерлы Россия Икътисадый үсеш министрлыгы боерыгы белән расланган);

урынга барып үткәрелгән тикшерү турында тикшерүләрне исәпкә алу журналына язып кую (мондый журнал булган очракта) (исәпкә алу журналының рәвеше Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 141 номерлы боерыгы белән расланган);

тикшерүләрнең бердәй реестрына 294-ФЗ номерлы Федераль законның 13.3 статьясы һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 415 номерлы карары нигезендә кертелгән мәгълүмат;

бозулар ачыкланганда:

бу Регламентның 1 таблицасындагы 1 һәм 3 пунктларында күздә тотылган ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозуларны юкка чыгару турында күрсәтмә (алга таба

– күрсәтмә), үтәү срогын күрсәтеп, бу срок бер айдан артмаска тиеш (бу Регламентка №1 кушымта нигезендәге форма буенча);

Татарстан Республикасы территориясендә рөхсәтләрнеңгамәлдә булуын үзара тану турында килешү төземәгән РФ субъекты вәкаләтле органында рөхсәт алган транспорт оешмасы тарафыннан җиңел таксида пассажирлар һәм багаж ташуны хәл итү шартларын бозу турында җиңел таксида пассажирлар һәм багаж ташу эшчәнлеген хәл итүгә рөхсәт биргән РФ субъектының вәкаләтле органына тапшырылган мәгълүмат. Россия Федерациясенең башка субъектлары территорияләре буенча җиңел таксида пассажирлар һәм багаж ташуны хәл итү җиңел таксины тапшыру пункты үзенеңвәкаләтле органы рөхсәт биргән Россия Федерациясе субъекты территориясендә урнашкан, ә билгеләнеш пункты әлеге Россия Федерациясе субъекты территориясеннән читтә урнашкан очракта гына рөхсәт ителә;

административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының11.14.1, 12.31.1 статьяларында күздә тотылган административ хокук бозу турында беркетмә (алга таба – беркетмә) (бу Регламентка №2 кушымта нигезендә);

административ хокук бозу турында эш буенча административ җәза билгеләү хакында карар (алга таба – карар) (бу Регламентка №3 кушымта нигезендә) яисә административ хокук бозу турында эшне тикшерүне туктату турында карар (бу Регламентка №4 кушымта нигезендә)

тапшырылган күрсәтмәне үтәмәү очрагында, бер айдан артмаган срокта рөхсәтнеңгамәлдә булуын туктатып тору (шул исәптән әлеге күрсәтмәне үтәү турында хисап әлеге күрсәтмәдә билгеләнгән срок чыкканчы Министрлыкка тапшырылмаган яки тапшырылган хисап әлеге күрсәтмәне билгеләнгән срокта үтәүне расламаган очракта);

рөхсәтнең гамәлдә булуын туктатып тору турында тапшырылган рөхсәтләр реестрына язу кертү;

бу Регламентның1 таблицасындагы 4 пунктында күздә тотылган таләпләрне кабат бозу;

бу Регламентның1 таблицасындагы 1.1-1-4 пунктчаларында күздә тотылган таләпләрне кабат бозу очрагында, рөхсәтнеңгамәлдә булу срогы дәвамында, рөхсәтнеңгамәлдә булуын туктатып тору срогы дәвамында мәҗбүри таләпләрне бозуларны юкка чыгару турында бирелгән күрсәтмәне үтәмәү;

күрсәтелгән срок чыкканчы тапшырылган күрсәтмәне үтәү турында хисап анынүтәлешен расламаганда, бу Регламентның 1 таблицасындагы 2 пунктында күздә тотылган таләпләрне бозулар ачыкланганда, җиңел таксида пассажирлар һәм багаж ташу эшчәнлеген хәл итүгә рөхсәтне кире алу (юкка чыгару) турында судка гариза;

бирелгән рөхсәтләр реестрына кертелгән, рөхсәтне кире алу (юкка чыгару) турында язу (суд карары нәтиҗәләре буенча);

Дәүләт вазыйфасын үтәүгә нигез булып Министрлыкка гражданнардан, юридик затлардан, индивидуаль эшкуарлардан мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар, дәүләт хакимияте органнарыннан, вәкаләтле органныңвазыйфаи затларыннан, җирле үзидарә органнарыннан һәм массакүләм мәгълүмат чараларыннан бу Регламентның1

таблицасындагы 3.1-3.3 пунктларында күрсәтелгән таләпләрне бозу фактлары турында мәгълүмат алыну торган очракта, бу бозу кешеләрнеңтормышы һәм сәламәтлегенә, әйләнә тирә мохиткә, физик һәм юридик затларныңмилкенә зыян китерү, аварияләр һәм (яки) техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр куркынычы ихтималына китерсә, яисә мондый зыян салуга һәм аварияләр һәм (яки) техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгуга китерсә, дәүләт вазыйфасын үтәү нәтиҗәләре буенча мөрәҗәгать итүчегә №59-ФЗ Федераль законда билгеләнгән тәртиптә җавап җибәрелә.

## 2. ДӘҮЛӘТ ВАЗЫЙФАСЫН ҮТӘҮ ТӘРТИБЕНӘ КАРАТА ТАЛӘПЛӘР

### ДӘҮЛӘТ ВАЗЫЙФАСЫН ҮТӘҮ ТУРЫНДА МӘГЪЛҮМАТ ҖИТКЕРҮ ТӘРТИБЕ

2.1. Министрлыкның урнашу урыны һәм эш графигы турында мәгълүмат:

Министрлыкның урнашу урыны: 420061, Татарстан Республикасы, Казан ш., Николай Ершов 31”а” й.

2.2. Документлар, мөрәҗәгатьләр җибәрү өчен почта адресы: 420061, Татарстан Республикасы, Казан ш., Николай Ершов ур., 31“а” й.

2.3. Министрлыкның эш графигы:

дүшәмбе-пәнҗешәмбе 8.30дан 17.30 сәгатькәчә;

җомга – 8.30дан 16.15 сәгатькәчә, төшке аш вакыты: 12.00 дән 12.45 сәгатькәчә;

шимбә, якшәмбе – ял көннәре.

2.4. Бүлек телефоны: (843) 291-20-22, 291-91-83, 219-91-70.

Дәүләт вазыйфасын үтәү тәртибе турында мәгълүмат Министрлыкныңрәсми сатына (http://mindortrans.tatarstan.ru) урнаштырылган.

Министрлыкка электрон мөрәҗәгатьләр җибәрү өчен электрон почта адресы: mindortrans@tatar.ru.

2.5. Кызыксынулы затларга дәүләт вазыйфасын үтәү мәсьәләләре буенча мәгълүмат, дәүләт вазыйфасын үтәү барышы турында мәгълүмат тәкъдим ителә:

“Интернет” (http://www. http://mindortrans.tatarstan.ru/) мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Министрлыкның рәсми сайтында мәгълүматны урнаштыру аша;

“Татарстан Республикасы Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы” республика дәүләт мәгълүмати системасында (http://uslugi.tatar.ru) (алга таба – Портал) мәгълүматны урнаштыру аша;

mindortrans.tatarstan.ru электрон почтасы аша;

язмача рәвештә (бу Регламентның 2.2 пунктында күрсәтелгән почта, адрес аша мөрәҗәгать иткәндә);

телдән, телефон аша мөрәҗәгать иткәндә яйсә Министрлыкка шәхсән мөрәҗәгать иткәндә.

Телдән мөрәҗәгатькә җавап мөрәҗәгать иткәннән соң кичекмәстән бирелә. Язмача мөрәҗәгатькә һәм (яки) электрон почта аша мөрәҗәгатькә җавап

Министрлыкка мөрәҗәгать иткән кызыксынулы затның почта адресына яки электрон адресына, Министрлыкта әлеге мөрәҗәгать теркәүгә алынганнан соң, календарь көннәрендә хисаплаганган утыз көнлек срок эчендә, җибәрелә һәм җавапларда куелган сорауларга җавап, башкаручының фамилиясе, инициаллары һәм телефон номеры булырга тиеш.

Телефоны алган Министрлыкның вазыйфаи затының куелган сорауларга мөстәкыйль җавап бирү мөмкинлеге булмаганда, телефон звоногы башка вазыйфаи затка күчерелергә яки мөрәҗәгать иткән кешегә кирәкле мәгълүмат алу мөмкин булган телефон номеры хәбәр ителергә тиеш.

Министрлыкның рәсми сайтына Министрлыкның мәгълүмати стендына түбәндәге мәгълүматлар урнаштырыла:

а) Министрлыкның урнашу урыны, дәүләт функциясен башкару тәртибе турында мәгълүмат бирә алырлык вазыйфаи затларның эш графигы, телефоннары һәм факс номерлары, электрон почта адресы;

б) җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өлкәсендә Россия Федерациясе законнарының һәм Татарстан Республикасы законнарының төп нигезләмәләре турында дәүләт функциясен башкаруга кагылышлы мәгълүмат;

в) хокук бозуларны профилактикалауның ел саен раслана торган программасы;

г) үтәлеше региональ дәүләт контроле (күзәтчелеге) тарафыннан бәяләнә торган мәҗбүри таләпләр язылган норматив хокукый актлар яисә аларның аерым өлешләре исемлеге, шулай ук тиешле норматив хокукый актларның текстлары;

д) мәҗбүри таләпләрнең үтәлешенә караган мәгълүмат, шул исәптән мәҗбүри таләпләрне үтәү буенча басылып чыккан күрсәтмәләр, семинарлар һәм конференцияләр үткәрү, массакүләм мәгълүмат чараларында аңлату эшләре алып бару турында белешмәләр, башка төрле юллар белән таратылган белешмәләр. Мәҗбүри таләпләр үзгәргән очракта, мәҗбүри таләпләрне билгели торган яңа норматив хокукый актларның эчтәлеге, гамәлдәге актларга кертелгән үзгәрешләр, аларның гамәлгә керү сроклары һәм тәртибе турында комментарийлар, шулай ук мәҗбүри таләпләрне кертүне һәм үтәүне тәэмин итүгә юнәлдерелгән кирәкле оештыру чаралары, техник чаралар үткәрү турында тәкъдимнәр урнаштырыла;

е) региональ дәүләт контролен гамәлгә ашыру тәҗрибәсен даими рәвештә, елына кимендә бер тапкыр гомумиләштерү, шул исәптән мәҗбүри таләпләрне бозуның аеруча еш очрый торган очраклары һәм  мондый хокук бозуларны булдырмау өчен юридик затлар, индивидуаль эшкуарлар тарафыннан күрелергә тиешле чаралар турында тәкъдимнәр булган мәгълүмат;

ж) бу Регламент (Министрлык бинасында мәгълүмати стендта бу Регламентныңаерым өзекләре урнаштырыла);

з) министр боерыгы белән расланган планлы тикшерүләр үткәрүнеңеллык планы (алга таба – еллык План);

и) дәүләт вазыйфасын үтәү барышында хәл ителгән гамәлләргә (гамәл кылмау) һәм  кабул ителгән карарларга шикаять белдерү тәртибе;

к) дәүләт вазыйфасын үтәүдә гамәлләрнеңэзлеклелеген чагылдыручы блок-схема

(бу Регламентка №5 кушымта).

## КОНТРОЛЬ ЧАРАЛАР ҮТКӘРГӘН ӨЧЕН ЮРИДИК ЗАТЛАРДАН ҺӘМ ИНДИВИДУАЛЬ ЭШКУАРЛАРДАН ТҮЛӘҮ АЛУНЫҢ ТЫЕЛУЫ

2.8. Төбәк дәүләт контрольлегеге чараларын үткәргән өчен юридик затлардан, индивидуаль эшкуарлардан түләү алынмый, шул исәптән, тикшерү үткәрүгә җәлеп итү очрагында, экспертлар һәм экспертлар оешмалары хезмәте күрсәтүгә түләү алынмый.

## ДӘҮЛӘТ ВАЗЫЙФАСЫН ҮТӘҮ СРОГЫ

2.9. Тикшерүләрнең һәркайсын (документар (планлы яки планнан тыш) шулай ук күчмә тикшерү (планлы яки планнан тыш) үткәрү срогы егерме эш көненнән артмаска тиеш.

2.10. Бер кече эшкуарлек субъектына карата планлы күчмә тикшерүләр үткәрүнең гомуми срогы кече предприятие өчен елына илле сәгатьтән һәм микропредприятие өчен – унбиш сәгатьтән артмаска тиеш.

2.11. Күчмә планлы тикшерү үткәрүче Министрлыкның вазыйфаи затларының нигезле тәкъдимнәре буенча, катлаулы һәм (яки) озакка сузылган тикшеренүләр, сынаулар, махсус экспертизалар һәм эзләнүләр үткәрү зарурилыгы белән бәйле чыгарма очракларда планлы күчмә тикшерү үткәрү срогы министр тарафыннан озайтылырга мөмкин, әмма күп дигәндә егерме эш көненә генә, кече предприятиеләргә карата - күп дигәндә илле сәгатькә, микропредприятиеләргә карата – күп дигәндә унбиш сәгатькә.

2.12. Кече эшкуарлык субъектына урынга барып планлаштырылган тикшерү үткәргәндә ведомствоара мәгълүмат алмашу кысаларында документлар һәм (яисә) мәгълүмат алу зарурлыгы туган очракта, тикшерү министр (министр урынбасары) тарафыннан ведомствоара мәгълүмат алмашу өчен кирәкле вакытка, ләкин ун эш көненнән дә артыграк вакытка түгел, туктатылырга мөмкин. Тикшерү үткәрүне кабат туктатып тору рөхсәт ителми.

Тикшерү үткәрүне туктатып тору срогы гамәлдә булган чорга кече эшкуарлык субъекты территориясендә, биналарында, корылмаларында, төзелмәләрендә, урыннарында һәм башка объектларында Министрлыкның күрсәтелгән тикшерүгә бәйле гамәлләре дә туктатыла.

## ПЛАНЛЫ ТИКШЕРҮНЕҢ НИГЕЗЕ

2.13. Юридик затларны, индивидуаль эшкуарларны планлы тикшерүләр билгеләнгән тәртиптә эшләнеп, министр тарафыннан расланган еллык план нигезендә үткәрелә. Еллык планнар билгеләнгән тәртиптә прокуратура органнары белән килештерелә һәм Министрлыкныңрәсми сайтына урнаштырыла.

2.14. Планлы тикшерүне Еллык планга кертүгә нигез булып:

1) юридик затка яки индивидуаль эшкуаргә беренче рөхсәт бирелгәннән соң;

2) юридик затка яки индивидуаль эшкуаргә соңгы планлы тикшерү үткәрү төгәлләнгәннән соңбер ел узу.

## ПЛАННАН ТЫШ ТИКШЕРҮ НИГЕЗЕ

2.16. Планнан тыш тикшерүгә нигез булып тора:

1) Министрлыкка күрсәтмәне үтәү турында хисап (алга таба – Хисап) (бу Регламентка №6 кушымта нигезендә) һәм мондый мәгълүматлардан торган документлар алынганда, мәҗбүри таләпләрне бозуларны юкка чыгару турында күрсәтмә үтәлешен раслаучы мәгълүматларны тикшерү яйсә элек бирелгән мәҗбүри таләпләрне бозуларны юкка чыгару турында күрсәтмә үтәлүнең сроклы чыгу;

2) Министрлыкка гражданнардан, юридик затлардан, индивидуаль эшкуарлардан мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар, дәүләт хакимияте органнарыннан, Министрлыкныңвазыйфаи затларыннан, җирле үзидарә органнарыннан һәм массакүләм мәгълүмат чараларыннан бу Регламентның1 таблицасындагы 3.1-3.3 пунктларында күрсәтелгән таләпләрне бозу фактлары турында мәгълүмат алыну, мондый бозу кешеләрнеңтормышы һәм сәламәтлегенә, әйләнә-тирә мохиткә, физик һәм юридик затлар милкенә зыян салу, аварияләр һәм (яки) техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу куркынычын тудырганда яисә мондый зыянга һәм аварияләр һәм (яки) техноген характердагы техноген хәлләр килеп чыгару китергәндә;

3) Россия Федерациясе Президенты, Россия Федерациясе Хөкүмәте поручениесе нигезендә чыгарылган планнан тыш тикшерү үткәрү турында министр боерыгыныңбулуы;

4) прокуратура органнарына алынган материаллар һәм мөрәҗәгатьләр буенча законнар үтәлешенә күзәтчелек кысаларында планнан тыш тикшерү үткәрү турында прокурор таләбе.

2.17. Мәҗбүри таләпләр бозуларны бетерү турында күрсәтмәне юридик затның, индивидуаль эшкуарның үтәү срогы тәмамлану планлаштырылмаган тикшерү үткәрү өчен нигез булган очракта, мондый тикшерүнең предметы бары тик Министрлык тарафыннан бирелгән күрсәтмәнең үтәлешен тикшерү генә булырга мөмкин.

2.18. Бу Регламентның 2 пунктчасының 2.16 пунктында күрсәтелгән планнан тыш күчмә тикшерү, кичекмәстән чаралар күрү зарурилыгына бәйле рәвештә, Министрлык тарафыннан, егерме дүрт сәгать эчендә прокуратура органнарына билгеләнгән тәртиптә кичекмәстән хәбәр итеп, үткәрелергә мөмкин. Бу Регламентның 2 пунктчасының 2.16 пунктында күрсәтелгән нигез буенча планлы күчмә тикшерү үткәрү турында юридик затка яки индивидуаль эшкуаргә алдан хәбәр итү таләп ителми.

2.19. Министрлыкка мөрәҗәгать иткән затны билгеләү мөмкинлеге бирмәгән мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар, шулай ук бу Регламентның 2 пунктчасының 2.16 пунктында күрсәтелгән фактлар турында мәгълүматлардан тормаган мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар планнан тыш тикшерү үткәрүгә нигез булып хезмәт итә алмый.

кешеләрнеңт ормышы һәм сәламәтлегенә, әйләнә тирә мохиткә, физик һәм юридик затларныңмилкенә зыян китерү куркынычы, аварияләр һәм (яки) техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр китереп чыгару куркынычы яисә мондый зыян килү һәм аварияләр һәм (яки) техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу фактлары турында мәгълүматлардан тормаган мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар планнан тыш тикшерү үткәрүгә нигез булып хезмәт итә алмый.

Мөрәҗәгатьтә яки гаризада бәян ителгән мәгълүмат әлеге Регламентның 2.16 пунктындагы 2 пунктчасы нигезендә планлаштырылмаган тикшерү үткәрү өчен нигез булган очракта, Министрлыкның вазыйфаи заты, мөрәҗәгатьнең яки гаризаның авторына карата шиге туса, мөрәҗәгать иткән затны ачыклау буенча мөмкин булган чаралар күрергә тиеш. Электрон документ рәвешендә җибәрелгән мөрәҗәгать һәм гариза мөрәҗәгать итүченең бердәм идентификация һәм аутентификация системасында мәҗбүри теркәлүе күздә тотыла торган мәгълүмат-коммуникация технологияләре чараларыннан файдаланып җибәрелгән очракта гына планнан тыш тикшерү үткәрү өчен нигез була ала.

2.20 Мөрәҗәгатьләрне һәм гаризаларны, әлеге Регламентның 2.16 пунктындагы 2 пунктчасында күрсәтелгән фактлар турында мәгълүматны караганда, аларга охшаш элек кергән мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар, мәгълүмат, шулай ук тиешле юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга карата элек үткәрелгән контроль чараларының нәтиҗәләре истә тотылырга тиеш.

2.21. Мәҗбүри таләпләрне бозуга юл куйган зат турында дөрес мәгълүмат, мәҗбүри таләпләр бозылу йә әлеге Регламентның 2.16 пунктындагы 2 пунктчасында күрсәтелгән фактлар турында җитәрлек белешмәләр булмаган очракта, Министрлыкның вазыйфаи затлары кергән мәгълүматны алдан тикшерү үткәрә ала. Алдан тикшерү барышында гаризалар һәм мөрәҗәгатьләр җибәргән, мәгълүмат китергән затлардан өстәмә белешмәләр һәм материаллар соратып алына (шул исәптән телдән), юридик затның, индивидуаль эшкуарның Министрлык карамагында булган документлары карала. Алдан тикшерү кысаларында алынган мәгълүматка карата юридик заттан, индивидуаль эшкуардан аңлатмалар соратып алырга мөмкин, ләкин мондый аңлатмаларны һәм башка документларны тапшыру мәҗбүри түгел.

2.22. Алдан үткәрелгән тикшерү нәтиҗәсендә мәҗбүри таләпләрнең бозылуына юл куйган затлар ачыкланганда, мәҗбүри таләпләрнең бозылуы турында йә әлеге пунктның 2 пунктчасында күрсәтелгән фактлар хакында җитәрлек белешмәләр тупланса, Министрлыкның вазыйфаи заты әлеге Регламентның 2.16 пунктындагы 2 пунктчасында күрсәтелгән нигезләр буенча планнан тыш тикшерү үткәрү турында дәлилләнгән күрсәтмә әзерли. Алдан үткәрелгән тикшерү йомгаклары буенча юридик зат, индивидуаль эшкуар җавапка тартылмый.

2.23. Алдан үткәрелә торган тикшерү, планнан тыш тикшерү башланганнан соң мондый тикшерүне оештыруның сәбәбе булган мөрәҗәгатьнең яки гаризаның аноним, йә мөрәҗәгатьтә яки гаризада булган белешмәләрнең ялган булуы ачыкланса, мондый тикшерү Министр (министр урынбасары) карары буенча туктатыла.

2.24. Гаризаларда, мөрәҗәгатьләрдә белә торып ялган белешмәләр күрсәтелгән булса, Министрлыкның граждан, шул исәптән юридик зат, индивидуаль эшкуар гаризаларын, мөрәҗәгатьләрен каруга бәйле чыгымнарын күрсәтелгән затлардан түләтү турында Министрлык судка мөрәҗәгать итәргә мөмкин.

2.25.Юридик затларны, индивидуаль эшкуарларны планнан тыш тикшерү, мондый юридик затлар, индивидуаль эшкуарлар эшчәнлеген башкара торган урын буенча прокуратура органы белән килештергәннән соң, әлеге Регламентның 2.16 пунктындагы 2 пунктчасында күрсәтелгән нигездә үткәрелергә мөмкин.

Урынга барып планнан тыш тикшерү үткәрүне прокуратура органы белән килештерү турында гаризаның үрнәк рәвеше Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 141 номерлы боерыгы белән расланган.

## РЕГИОНАЛЬ ДӘҮЛӘТ КОНТРОЛЕН ҮТКӘРӘ ТОРГАН ВАЗЫЙФАИ ЗАТЛАР

2.26. Төбәк дәүләт контрольлеген министр (министр урынбасары) боерыгы нигезендә тикшерү үткәрүгә вәкаләт бирелгән вазыйфаи затлар тарафыннан турыдан-туры хәл ителә.

Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксида пассажирлар һәм багаж ташу өлкәсендә административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә, административ хокук бозулар турында эшләрне карап тикшерүгә хокуклы вазыйфаи затлар исемлеге Министрлык боерыгы белән раслана.

## 294-ФЗ НОМЕРЛЫ ФЕДЕРАЛЬ ЗАКОННЫ БОЗГАН ӨЧЕН ЮРИДИК ЗАТЛАРНЫҢ, ИНДИВИДУАЛЬ ЭШКУАРЛАРНЫҢЖАВАПЛЫЛЫГЫ

2.27. Тикшерүләр үткәрелгәндә, юридик затлар юридик затларныңҗитәкчеләре, башка вазыйфаи затлары яки вәкаләтле вәкилләре катнашуын тәэмин итәргә; индивидуаль эшкуарлар үзләре катнашырга яки мәҗбүри таләпләрне үтәү чараларын оештыру һәм үткәрү өчен җаваплы вәкаләтле вәкилләрнең катнашуын тәэмин итәргә тиеш.

2.28. 294-ФЗ номерлы Федераль законны бозуга юл куйган, тикшерүләр үткәрүгә нигезсез комачаулаган, тикшерүләр үткәрүдән качып йөргән һәм (яки) ачыкланган бозуларны юкка чыгару турында Министрлык күрсәтмәсен билгеләнгән срокта үтәмәгән юридик затлар, аларның җитәкчеләре, башка вазыйфаи затлар яки юридик затларның вәкаләтле вәкилләре, индивидуаль эшкуарлар, аларның вәкаләтле вәкилләре Россия Федерациясе законы нигезендә җавап бирә.

## МИНИСТРЛЫКНЫҢ, ВАЗЫЙФАИ ЗАТЛАРНЫҢТИКШЕРҮ ҮТКӘРҮДӘ ҖАВАПЛЫЛЫГЫ

2.29. Министрлык, аның вазыйфаи затлары тикшерү үткәргәндә үз

вазыйфаларын, хезмәт бурычларын тиешенчә үтәмәгән, хокукка каршы гамәлләр кылган (гамәл кылмау) очракта, Россия Федерациясе законы нигезендә җавап бирә.

2.30. Россия Федерациясе законнарын һәм Татарстан Республикасы законнарын бозуда гаепле вазыйфаи затларга карата күрелгән чаралар турында, мондый чаралар күрелгәннән соңун көн эчендә Министрлык хокуклары һәм (яки) законлы мәнфәгатьләре санга сугылмаган юридик затка, индивидуаль эшкуаргә язмача рәвештә хәбәр итәргә тиеш.

## 3. ЮРИДИК ЗАТЛАРГА ҺӘМ ИНДИВИДУАЛЬ ЭШКУАРЛАРГА КАРАТА КУЕЛА ТОРГАН МӘҖБҮРИ ТАЛӘПЛӘР

3.1. Юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга карата куелып үтәлеше контрольдә тотыла торган мәҗбүри таләпләр, мәҗбүри таләпләрне билгеләүче норматив-хокукый актлар, тикшерү үткәрелгәндә юридик затлар, индивидуаль эшкуарлар күрсәтергә тиешле документлар исемлеге 1 нче таблицада китерелә.

3.2. Юридик затларның, индивидуаль эшкуарларның мәҗбүри таләпләрне бозуларын кисәтү, мәҗбүри таләпләрне бозуга китерә торган сәбәпләрне, факторларны һәм шартларны бетерү максатларында, Министрлык хокук бозуларны профилактикалау буенча ел саен раслана торган программалар нигезендә мәҗбүри таләпләрне бозуларны профилактикалау чараларын үткәрә.

3.3. Мәҗбүри таләпләрне бозуларны профилактикалау максатларында Министрлык мәҗбүри таләпләрне бозуның тыелуы турында 294-ФЗ номерлы Федераль законның 8.2 статьясындагы 5 – 7 өлешләрендә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 166 номерлы карарында билгеләнгән тәртип нигезендә кисәтүләр ясый һәм юридик затка, индивидуаль эшкуарга мәҗбүри таләпләрне үтәүне тәэмин итү чараларын күрергә һәм Министрлыктан алынган кисәтүдә күрсәтелгән срокларда бу хакта хәбәр итәргә тәкъдим итә.

3.4. Мәҗбүри таләпләрне бозуның тыелуы турында кисәтүне төзү һәм җибәрү, юридик затның, индивидуаль эшкуарның мондый кисәтүгә ризасызлык белдерү һәм аларны карау, мондый кисәтүне үтәү турында хәбәр итү кагыйдәләре Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 166 номерлы карары белән расланган.

1 таблица

## Юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга карата куела торган мәҗбүри таләпләр исемлеге

| Контрольдә тотыла торган объектлар (эшчәнлек төрләре, контрольлек төрләре) | Мәҗбүри таләп формиулировкасы | Мәҗбүри таләпне билгеләүче норматив-хокукый акт | Тикшерү үткәргәндә юридик затлар, индивидуаль эшкуарлар тарафыннан күрсәтелә торган документлар исемлеге) |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. Җиңел таксига карата торган куела торган таләпләр | 1.1. Кузовында (кузовыныңян-ягы өслекләрендә) шахмат тәртибендә урнаштырылган, контраст төсләрдә шакмаклардан торган төс схемасы | № 69-ФЗ Федераль законның 9 статьясындагы 16 өлешенең 1 пунктындагы “б” пунктчасы; Кагыйдәләрнең116 пункты | Күчмә тикшерүләр вакытында җиңел таксиларны карауда тикшерелә, документлар соратып алынмый |
| | 1.2. Җиңел такси кузовыныңтөсе, кузовныңбилгеләнгән төсләргә (сары яки ак төсләр) туры килүе | № 69-ФЗ Федераль законның 9 статьясындагы 16 өлешенең 1 пунктындагы “в” пунктчасы; № 77-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 4 статьясындагы 2 өлешенең 1 пункты | Күчмә тикшерүләр вакытында җиңел таксиларны карауда тикшерелә |
| | 1.3. Җиңел такси өстендә кызгылт сары төстәге фонарьнеңбулуы | № 69-ФЗ Федераль законның 9 статьясындагы 16 өлешенең 1 пунктындагы “г” пунктчасы; Кагыйдәләрнең115 пункты | Күчмә тикшерүләр вакытында җиңел таксиларны карауда тикшерелә, документлар соратып алынмый |
| | 1.4. Җиңел таксидан файдалануга түләү, пассажирныңалып баруныңфакттагы ераклыгыннан һәм (яки) җиңел таксидан файдалануныңфакттагы вакытыннан чыгып билгеләнгән тарифлар нигезендә таксометр күрсәткечләре буенча билгеләнгән очракта, таксометрныңбулуы | № 69-ФЗ Федераль законның 9 статьясындагы 16 өлешенең 1 пунктындагы “д” пунктчасы; Кагыйдәләрнең 110 пункты | Күчмә тикшерүләр вакытында җиңел таксиларны карауда тикшерелә, документлар соратып алынмый |
| | 1.5. Җиңел таксида автомобиль салонының алдагы панелендә түбәндәге мәгълүматларның булуы:<br>– фракхтовщикның(юридик зат яки индивидуаль эшкуар) тулы яки кыскача атамасы;<br>җиңел таксидан файдалануга түләү шартлары;<br>фотосурәте белән машина йөртүченеңвизит карточкасы:;<br>– Министрлыкның(пассажирлар һәм багаж ташуга контрольлекне тәэмин итүче орган) атамасы, адресы һәм | Кагыйдәләрнең 117 пункты | Күчмә тикшерүләр вакытында җиңел таксиларны карауда тикшерелә, документлар соратып алынмый |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | элемтәгә керү өчен телефоннары | | |
| 2.Җиңел такси йөртүчегә карата куела торган таләпләр | 2.1. Җиңел такси йөртүче кимендә өч еллык гомуми машина йөртү стажына ия булырга тиеш | № 69-ФЗ Федераль законның 9 статьясындагы 16 өлешенең 2 пункты | Пассажирларны һәм багажны җиңел таксида ташу хезмәте күрсәтү өчен транспорт чаралары белән идарә итүгә кертелгән затларныңмашина йөртү таныклыклары күчермәләре |
| 3. Пассажирларны һәм багажны җиңел таксида ташу хезмәте күрсәтү эшчәнлеге белән шөгыльләнүче юридик затка яки индивидуаль эшкуарларга карата куела торган таләпләр | 3.1. Җиңел таксига техник хезмәт күрсәтү һәм аны ремонтлау | № 69-ФЗ Федераль законның 9 статьясындагы 16 өлешенең 3 пунктындагы “а” пунктчасы; | Транспорт чарасына техник хезмәт күрсәтүгә һәм аны ремонтлауга килешү яки транспорт чарасын ремонтлауны һәм аңа хезмәт күрсәтүне раслаучы документ яисә тиешле квалификациягә ия булып, транспорт чараларына техник хезмәт күрсәтү һәм аларны ремонтлау буенча хезмәт күрсәтүче зат белән мөнәсәбәтләрне чагылдыра торган хезмәт килешүе (булганда, дәүләт техник каравын үтү турында талоннар (диагностика карталары) күчермәләре |
| | 3.2. Юлга чыкканчы, җиңел таксиныңтехник торышына контрольлек үткәрү | № 69-ФЗ Федераль законның 9 статьясындагы 16 өлешенең 3 пунктындагы “б” пунктчасы; | Юлга чыкканчы, рейс алдыннан техник контрольлек буенча хезмәт күрсәтүгә килешү яки тиешле квалификациягә ия булып, юлга чыга алдыннан җиңел таксиныңтехник торышына контрольлек үткәрүне хәл итүче зат белән хезмәт килешүе;<br>Юлга чыкканчы җиңел таксиныңтехник торышына контрольлек үткәрүне раслаучы документ |
| | 3.3. Җиңел такси йөртүчеләргә рейс алдыннан медицина каравын уздыру | № 69-ФЗ Федераль законның9 статьясындагы 16 өлешенең3 пунктындагы “в” пунктчасы; | Медицина хезмәтләре күрсәтүгә килешү яки тиешле медицина белеменә ия булып, медицина хезмәтләре күрсәтүче зат белән мөнәсәбәтләрне чагылдыра торган хезмәт килешүе (булганда); |
| | 3.4. Фрахтовщик фрахтовательгә җиңел таксидан файдалануга түләүне раслаучы касса чегы яки катгый хисап бланкы рәвешендәге квитанция бирә | Кагыйдәләрнең 111 пункты | Чек яки җиңел таксидан файдалануга түләүне раслаучы катгый хисап бланкы рәвешендәге квитанция |
| 4. Татарстан Республикасы территориясендә пассажирлар һәм багажны җиңел таксида ташу эшчәнлегенә карата таләп | Министрлыкта яки Татарстан Республикасы белән рөхсәтләрнең гамәлдә булуын үзара тану турында килешү төзегән РФ субъектыныңвәкаләтле органында җиңел таксида пасажирлар һәм багаж ташуга рөхсәт алган транспорт оешмасы тарафыннан җиңел таксида пассажирлар һәм багаж ташуны хәл итү шартларын үтәү | № 69-ФЗ Федераль законның 9 статьясындагы 1.4 өлеше | Җиңел таксида пассажир һәм багаж ташу өчен вәкаләтле орган тарафыннан тапшырылган рөхсәт |

## 4. ТИКШЕРҮ ҮТКӘРГӘНДӘ ЮРИДИК ЗАТ, ИНДИВИДУАЛЬ ЭШКУАР ТАРАФЫННАН ТАПШЫРЫЛА ТОРГАН ДОКУМЕНТЛАР

Тикшерү максатлары һәм бурычларына ирешү өчен юридик зат, индивидуаль эшкуар тарафыннан тапшырыла торган документлар исемлеге, шулай ук мондый документларныңформаларын раслаучы норматив-хокукый актлар 2 нче таблицада китерелә

2 нче таблица

Тикшерү максатлары һәм бурычларына ирешү өчен юридик зат, индивидуаль эшкуар тарафыннан тапшырыла торган документлар исемлеге

| Тикшерү үткәрү өчен тапшырыла торган документ | Документныңформасын билгеләүче норматив-хокукый акт |
|---|---|
| 1. Җиңел таксида пассажирлдар һәм багаж ташу хезмәте күрсәтү өчен транспорт чаралары белән идарә итүгә кертлегән затларныңмашина йөртү таныклыклары күчермәләре | “Машина йөртү таныклыгын гамәлгә кертү турында” 13 май, 2009 ел, № 365 Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгы боерыгына № 1 кушымта |
| 2. Транспорт чарасына техник хезмәт күсрәтүгә һәм аны ремонтлауга килешү яки транспорт чарасын ремонтлауны һәм аңа хезмәт күрсәтүне раслаучы документ яисә тиешле квалификациягә ия булып, транспорт чараларына техник хезмәт күрсәтү һәм аларны ремонтлау хезмәте күрсәтүче зат белән мөнәсәбәтләрне чагылдыра торган хезмәт килешүе (булганда), дәүләт техник каравын үтү турында талоннар (диагностик карталар) күчермәләре | Россия Федерациясе Гражданлык кодексы,<br>“Автомототранспорт чараларына техник хезмәт күрсәтү һәм аларны ремонтлау буенча хезмәт күрсәтү (эшләр башкару) кагыйдәләрен расламау турында” 11.04.2001 ел, № 290 Россия Федерациясе Хөкүмәте карары,<br>Россия Федерациясе Хезмәт кодексы |
| 3. Юлга чыкканчы, рейс алдыннан техник контрольлек хезмәте күрсәтүгә килешү яки тиешле квалификациягә ия булып, юлга чыкканчы, җиңел таксиныңтехник торышын контрольдә тотуны хәл итүче зат белән хезмәт килешүе | Россия Федерациясе Гражданлык кодексы,<br>Россия Федерациясе Хезмәт кодексы |
| 4. Медицина хезмәтләре күрсәтүгә килешү яки тиешле медицина белеменә ия булып, медицина хезмәтләре күрсәтүче зат белән мөнәсәбәтләрне чагылдырган хезмәт килешүе | Россия Федерациясе Гражданлык кодексының779-783 ст.,<br>Россия Федерациясе Хезмәт кодексы |
| 5. Хезмәт килешүе яки тиешле машина йөртү стажына ия булып, Татарстан Республикасы территориясендә пассажирлар һәм багаж ташу хезмәте күрсәтүче зат белән | Россия Федерациясе Гражданлык кодексы,<br>Россия Федерациясе Хезмәт кодексы |

| | |
|---|---|
| мөнәсәбәтләрне чаглдырган башка документ | |
| 6. Машина йөртүчеләр тарафыннан рейс алды медицина каравын үтүне һәм юлга чыкканчы, җиңел таксиныңтехник торышына контрольлек үткәрүне раслаучы документ | “Мәҗбүри реквизитларны һәм юл кәгазьләрен тутыру тәртибен раслау турында” 18 сентябрь, 2008 ел, №152 Россия Федерациясе Транспорт министрлыгы боерыгы |
| 7. Җиңел таксидан файдалануга түләүне раслаучы чек яки катгый хисап бланкы рәвешендәге квитанция | Кагыйдәләргә № 5 кушымта |

## 5. АДМИНИСТРАТИВ ПРОЦЕДУРАЛАР (ГАМӘЛЛӘР) СОСТАВЫ, ЭЗЛЕКЛЕЛЕГЕ ҺӘМ АЛАРНЫ БАШКАРУ СРОКЛАРЫ, АЛАРНЫ БАШКАРУ ТӘРТИБЕНӘ КАРАТА ТАЛӘПЛӘР, ШУЛ ИСӘПТӘН ЭЛЕКТРОН РӘВЕШТӘ АДМИНИСТРАТИВ ПРОЦЕДУРАЛАРНЫ (ГАМӘЛЛӘРНЕ) ҮТӘҮ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

### АДМИНИСТРАТИВ ПРОЦЕДУРАЛАРНЫҢ СОСТАВЫ

5.1. Төбәк дәүләт контрольлеге планлы (документар һәм күчмә) һәм планнан тыш (документар һәм күчмә) тикшерүләр юлы белән хәл ителә.

5.2. Әлеге Регламентта түбәндәге административ процедуралар башкару карала:

а) юридик затка, индивидуаль эшкуаргә планлы документар тикшерү үткәрү;

б) юридик затка, индивидуаль эшкуаргә планлы күчмә тикшерү үткәрү;

в) юридик затны, индивидуаль эшкуарны документлар аша планнан тыш тикшерү;

г) юридик затны, индивидуаль эшкуарны урынга барып планнан тыш тикшерү.

5.3. Төбәк дәүләт контрольлеген оештыруның һәм хәл итүнең блок-схемасы бу Регламентка № 5 кушымтада китерелгән.

5.4. Дәүләт вазыйфасын үтәүне туктатып тору Россия Федерациясе законында каралган очракларда күздә тотыла.

### “ЮРИДИК ЗАТКА, ИНДИВИДУАЛЬ ЭШКУАРГӘ ПЛАНЛЫ ДОКУМЕНТАР ТИКШЕРҮ ҮТКӘРҮ” АДМИНИСТРАТИВ ПРОЦЕДУРАСЫ

5.5. Административ процедураны башлауга нигез булып тиешле юридик затны, индивидуаль эшкуарне еллык Планга кертү тора. Юридик затны, индивидуаль эшкуарне планлы документар тикшерүне Еллык Планга кертү бу Регламентның 2.14 пунктында күрсәтелгән нигезләр буенча хәл ителә.

Административ процедура түбәндәге административ гамәлләр тәртибендә хәл ителә:

тикшерү үткәрүгә җаваплы вазыйфаи затларны билгеләү;

тикшерү үткәрү турында боерык рәсмиләштерү, юридик затка,

индивидуаль эшкуаргә тикшерү үткәрү турында уведомление җиткерү;

тикшерү үткәрү;

тикшерү йомгаклары буенча тикшерү актын, башка документларны әзерләү;

юридик затны, индивидуаль эшкуарне тикшерү акты белән таныштыру;

тикшерү нәтиҗәләре буенча законда күздә тотылган чаралар күрү.

Планлаштырылган тикшерүнең предметы юридик затның, индивидуаль эшкуарның таләп ителә торган мәҗбүри таләпләрне эшчәнлек процессында үтәвен тикшерүдән гыйбарәт.

Документар тикшерү предметы булып үзләренеңоештыру хокукый формасын, хокукларын һәм бурычларын билгеләгән юридик зат, индивидуаль эшкуар документларындагы мәгълүматлар, үзләренеңэшчәнлеген хәл итүдә файдаланыла торган һәм үзләре тарафыннан мәҗбүри таләпләрне, Министрлык күрсәтмәләрен үтәүгә бәйле документлар тора.

5.6. Еллык План нигезендә, Бүлек, Идарә начальниклары юридик затка, индивидуаль эшкуаргә тикшерү үткәрү өчен Бүлекнең вазыйфаи затлары арасыннан җаваплы эш башкаручыларны (алга таба – җаваплы эш башкаручы) билгели:

Башкару срогы: тикшерү үткәрү башланганчы биш эш көненнән дә соңга калмыйча (тикшерү үткәрү турында юридик затка, индивидуаль эшкуаргә уведомление җиткерү өчен кирәкле вакытны исәпкә алмыйча).

Гамәл нәтиҗәсе: юридик затка, индивидуаль эшкуаргә тикшерү үткәрү өчен билгеләнгән җаваплы эш башкаручылар.

5.7. Җаваплы эш башкаручы:

юридик затка, индивидуаль эшкуаргә планлы документар тикшерү үткәрү турында боерык проекты әзерли (бу Регламентка №7 кушымта нигезендә);

планлы документар тикшерү үткәрү турында боерык проектын министрга (министр урынбасары) имза салуга җибәрә.

Башкару срогы: планлы документар тикшерү үткәрү башланганчы өч эш көненнән дә соңга калмыйча (планлы документар тикшерү үткәрү турында юридик затка, индивидуаль эшкуаргә уведомление җиткерү өчен кирәкле вакытны исәпкә алмыйча).

Гамәл нәтиҗәсе: планлы документар тикшерү үткәрү турында министр (министр урынбасары) имзалаган боерык.

5.8. Планлаштырылган тикшерү үткәрү турында юридик затка, индивидуаль эшкуарга планлаштырылган тикшерү үткәрү турында боерык күчермәсен тапшырылуы турында хәбәр ителә торган заказлы хат белән почта аша һәм (яисә) ныгытылган квалификацияле электрон имза куелган һәм юридик затның, индивидуаль эшкуарның электрон адресына җибәрелгән (әгәр мондый адрес юридик затларның бердәм дәүләт реестрында, индивидуаль эшкуарларның бердәм дәүләт реестрында булса йә дәүләт контроле

(күзәтчелеге) органына юридик зат, индивидуаль эшкуар тарафыннан элегрәк бирелгән булса) электрон документ рәвешендә яисә мөмкин булган башка ысул белән җаваплы башкаручы тарафыннан  җибәреп хәбәр ителә.

Планлы документар тикшерү үткәрү турында юридик зат, индивидуаль эшкуар исеменә планлы документар тикшерү үткәрү турында боерык күчермәсен җибәрү Министрлыкта делопроизводство алып бару кагыйдәләре нигезендә билгеләнгән тәртиптә теркәлә.

Башкару срогы: планлы документар тикшерү үткәрүне башлаганчы өч эш көненнән дә соңга калмыйча.

Гамәл нәтиҗәсе: юридик затка, индивидуаль эшкуаргә планлы документар тикшерү үткәрү турында боерык күчермәсен җибәрү.

Министрлыкка тапшырыла торган документлар күчермәләрен нотариуста раслау таләп ителми, Россия Федерациясе законында башкача күздә тотылмаса.

Боерыкта күрсәтелгән документлар мөһер белән (булган очракта) таныкланган һәм индивидуаль эшкуар, аның вәкаләтле вәкиле, юридик зат җитәкчесе, башка вазыйфаи заты тарафыннан имза куелган күчермә рәвешендә тапшырыла. Юридик зат, индивидуаль эшкуар күрсәтмәдә билгеләнгән документларны ныгытылган квалификацияле электрон имза куелган электрон документ рәвешендә тапшырырга хаклы.

5.9. Планлы документар тикшерү үткәрү процессында җаваплы эш башкаручы Министр карамагында булып, билгеләнгән тәртиптә тапшырылган, юридик зат, индивидуаль эшкуар документларын, шул исәптән алдагы тикшерүләр актларын, административ хокук бозулар турында эшләрне карап тикшерү материалларын һәм юридик затка, индивидуаль эшкуаргә карата хәл ителгән дәүләт төбәк контрольлеге нәтиҗәләре турында башка документларны тикшерә.

Министрлык карамагындагы документларда урын алган мәгълүматларның дөреслеге нигезле шикләнүләр тудырса яки бу мәгълүматлар юридик зат, индивидуаль эшкуар тарафыннан мәҗбүри таләпләрнеңүтәлешен бәяләү мөмкинлеге бирмәсә, хаталар һәм (яки) каршылыклы мәгълүматлар ачыкланса, җаваплы эш башкаручы:

мәгълүматларны бәяләү нәтиҗәләре турында мәгълүмат һәм ун эш көне эчендә кирәкле аңлатмалар тапшыру яисә карап тикшерү өчен башка документларны тапшыру таләбе белән, юридик затка, индивидуаль эшкуаргә хат (нигезле запрос) әзерли;

хатны (нигезле запрос) министрга (министр урынбасары) имза салуга җибәрә;

имза салынганнан соңхатны (нигезле запрос) планлы документар тикшерү үткәрү турында министр (министр урынбасары) боерыгы күчермәсе (мөһер белән расланган) белән, юридик затка, индивидуаль эшкуаргә почта аша заказлы хат белән  (тапшыру турында уведомление белән) яки уңайлы башка

ысул белән (факсимиль элемтә, электрон почта, кулга тапшырып – алу турында билге белән) җибәрү һәм теркәү өчен Министрлыкныңдокументлар әйләнеше бүлегенә җибәрә.

Министрлык планлы документар тикшерү үткәргәндә юридик заттан, индивидуаль эшкуардән документар тикшерү предметына керми торган мәгълүматлар һәм документлар, шулай ук Министрлыкка башка дәүләт контрольлеге (күзәтчелек) органнарыннан, муниципаль контрольлек органнарыннан, шул исәптән ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша электрон рәвештә запрослар җибәрү ярдәмендә, мәгълүматлар һәм документлар таләп итүгә хокуклы түгел.

Җаваплы башкаручы, кирәк булган очракта, бу Регламентның 1.7 пункты таләпләре нигезендә билгеләнгән тәртиптә, шул исәптән электрон рәвештә документлар һәм (яисә) мәгълүмат соратып алырга мөмкин.

Башкару срогы: тикшерү үткәрү алдыннан соң биш эш көне эчендә.

Гамәл нәтиҗәсе: кирәкле документлар тапшыру таләбе белән юридик затка, индивидуаль эшкуаргә хат (нигезле запрос) җибәрү.

5.10. Запроста күрсәтелгән документлар, нигезле запрос алганнан соң 10 эш көне эчендә, Министрлыкка бу Регламентның 5.8 пунктында билгеләнгән тәртиптә тапшырыла.

Җаваплы башкаручы тапшырылган документларны һәм (яисә) аңлатмаларны карый. Тапшырылган документларны һәм (яисә) аңлатмаларны караганнан соң йә аңлатмалар булмаганда, әлеге Регламентның 3 бүлегендә күрсәтелгән мәҗбүри таләпләр бозылу билгеләре ачыкланса, җаваплы башкаручы, министр (министр урынбасары) исеменә  аңлатма (служебная записка) әзерләп, урынга барып тикшерү үткәрүне оештыра, аңлатмада мәҗбүри таләпләр бозылуның ачыкланган фактлары бәян ителә һәм  урынга барып тикшерүнең зарурлыгы дәлилләнә. Мондый очракта документлар аша тикшерү нәтиҗәсе урынга барып тикшерүне гамәлгә ашыра башлау өчен нигез белән һәм “Юридик затны, индивидуаль эшкуарны документлар аша планнан тыш тикшерү” административ процедурасы белән туры килә.

Башкару срогы: аңлатмалар һәм (яки) документлар алынганнан соңөч эш көне эчендә.

Гамәл нәтиҗәсе: юридик зат, индивидуаль эшкуар тарафыннан тапшырылган аңлатмаларны һәм (яки) документларны карап тикшерү; кирәк булганда, аңлатма (служебная записка).

Күчмә тикшерү (аны үткәрү турында карар кабул ителгәндә) бу Регламентның “Юридик затны, индивидуаль эшкуарны документлар аша планнан тыш тикшерү” бүлекчәсендә китерелгән тәртиптә хәл ителә.

Күчмә тикшерү үткәргәндә юридик заттан, индивидуаль эшкуардән документар тикшерү үткәрү барышында тәкъдим ителгән мәгълүматларны һәм (яки) документларны кабат таләп итү тыела.

5.11. Җаваплы эш башкаручы юридик зат, индивидуаль эшкуар документларындагы мәгълүматларны бәяләү нигезендә, ике нөсхәдә тикшерү акты төзи.

Контрольлек чаралары нәтиҗәсендә мәҗбүри таләпләрне бозуларны ачыкланган очракта җаваплы эш башкаручы түбәндәге гамәлләрне кыла:

ачыкланган барлык бозу очракларын тикшерү актында терки;

бу Регламентның 1 нче таблицасындагы 1.2, 3.1-3.3 пунктларында күздә тотылган мәҗбүри таләпләрне бозуларны юкка чыгару турында үтәү өчен мәҗбүри булып торган күрсәтмәләр (күрсәтмәнеңтиповой формасы бу Регламентка № 1 кушымтада китерелгән) бирә, аларны юкка чыгару турында срокларны (күп дигәндә бер ай вакыт) күрсәтеп һәм (яки) кешеләр тормышына, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни ядкәрләр), дәүләт иминлегенә, физик һәм юридик затлар милкенә, дәүләти яки муниципаль милеккә зыян китерүне кисәтү, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрнеңкилеп чыгуын кисәтү буенча чаралар, шулай ук федераль законнарда күздә тотылган башка чаралар үткәрү турында күрсәтеп (тикшерү актына кушымта булып тора), һәм әлеге күрсәтмәләрнеңбилгеләнгән срокларда үтәлүенә контрольлек итә;

РФ КоАП 11.14.1, 12.31.1 статьяларында күздә тотылган административ хокук бозу билгеләре ачыкланганда бу Регламентка  2 кушымтада китерелгән типовой форма нигезендә беркетмә төзи һәм аны бу Регламентның 5.13 пункты нигезендә карап тикшерүне тәэмин итә.

Күрсәтмәне тикшерү актына имза куелганнан соң һәм ул тапшырылганнан соң әзерләү, рәсмиләштерү һәм тапшыру рөхсәт ителми.

Тикшерү нәтиҗәләре буенча беркетмә төзү очрагында, җаваплы эш башкаручы беркетмәне административ хокук бозу турында эшне карап тикшерүгә вәкаләтле вазыйфаи затка җибәрә.

Башкару срогы:

тикшерү актын (шул исәптән күрсәтмә) төзү – турыдан-туры тикшерү төгәлләнгәннән соң;

беркетмә төзү – кичекмәстән административ хокук бозу ачыкланганнан соң;

административ хокук бозулар турында эшне карап тикшерүгә вәкаләтле вазыйфаи затка беркетмә җибәрү – беркетмә төзелгәннән соңөч көн эчендә.

Гамәл нәтиҗәсе:

кушымталар белән тикшерү акты – ике нөсхәдә;

мәҗбүри таләпләр ачыкланганда:

күрсәтмә;

административ хокук бозу турында эшне карап тикшерүгә вәкаләтле вазыйфи затка беркетмә җибәрү.

5.12. Җаваплы эш башкаручы тикшерү актының бер нөсхәсен (кушымталары белән бергә) делога тегеп куя, икенчесен (кушымталары белән бергә) юридик зат җитәкчесенә, башка вазыйфаи затына яки вәкаләтле вәкиленә, индивидуаль эшкуаргә, тикшерү акты белән танышу турында яки танышудан баш тарту турында имза салдырып, тапшыра.

Юридик зат җитәкчесе, башка вазыйфаи заты яки вәкаләтле вәкиле, индивидуаль эшкуар булмаган очракта, тикшерелә торган зат тикшерү акты белән танышу яки танышудан баш тарту турында имза салуны инкарь иткән очракта акт почта аша заказлы хат белән (тапшыру турында уведомление белән) җибәрелә, уведомление Министрлык делосында саклана торган тикшерү акты нөсхәсе янына куела.

Тикшерелә торган затның региональ дәүләт контроле кысаларында электрон рәвештә хезмәттәшлек итүгә рөхсәте булган очракта, тикшерү акты мондый актны төзегән затның ныгытылган квалификацияле электрон имзасы куелган электрон документ рәвешендә юридик зат җитәкчесенә, башка вазыйфаи затына яисә вәкаләтле вәкиленә, индивидуаль эшкуарга, аның вәкаләтле вәкиленә җибәрелергә мөмкин. Актны төзегән затның ныгытылган квалификацияле электрон имзасы куелган электрон документ рәвешендә, бу документны алуны раслый торган ысул белән җибәрелгән акт тикшерелә торган зат тарафыннан алынган дип санала.

Тикшерү үткәрелгән юридик зат, индивидуаль эшкуар тикшерү актында бәян ителгән фактлар, чыгарылмалар, тәкъдимнәр белән йә ачыкланган хокук бозуларны бетерү турында күрсәтмә белән килешмәгән очракта, тикшерү актын алган датадан башлап унбиш көн өчендә Министрлыкка тикшерү актына һәм (яисә) ачыкланган хокук бозуларны бетерү турында күрсәтмәгә (тулысынча йә аның аерым нигезләмәләренә) карата язмача ризасызлык белдерү хокукына ия. Юридик зат, индивидуаль эшкуар мондый ризасызлыкның дәлилләнгән булуын раслый торган документларны яисә аларның танықланган күчермәләрен ризасызлыкка кушымта итеп өстәргә яки аларны килешенгән срокта Министрлыкка тапшырырга хокуклы. Күрсәтелгән документлар тикшерелә торган затның ныгытылган электрон имзасы белән имзаланган электрон документлар (электрон документлар пакеты) рәвешендә җибәрелергә мөмкин.

Башкару срогы:

юридик затны, индивидуаль эшкуарне тикшерү акты белән танышу, юридик затка, индивидуаль эшкуаргә тикшерү акты белән танышу турында яки танышудан баш тарту турында имза салдырып тикшерү актын тапшыру – турыдан-туры тикшерү төгәлләнгәннән соң;

тикшерү актын заказлы хат белән җибәрү – төбәк дәүләт контрольлеге чаралары төгәлләнгәннән соңбер эш көне эчендә.

Гамәл нәтиҗәсе: юридик затны, индивидуаль эшкуарне тикшерү акты белән таныштыру юридик затка, индивидуаль эшкуаргә тикшерү акты тапшыру

(җибәрү).

5.13. Тикшерү нәтиҗәләре буенча бозулар ачыкланган очракта Министрлык юридик затка, индивидуаль эшкуаргә карата Россия Федерациясе законы һәм Татарстан Республикасы законы нигезендә тиешле чаралар күрә:

ачыкланган бозуларны юкка чыгару турында күрсәтмәләр бирә;

административ хокук бозу турында беркетмә төзи;

бу Регламентның 5.14, 5.15 пунктлары нигезендә, административ хокук бозу турында эш буенча административ җәза билгеләү турында карар яки административ хокук бозу турында эш буенча тикшерүне туктату турында карар бирә;

ачыклау, кисәтү һәм киртә кую мәсьәләләре Министрлык компетенциясенә кермәгәндә, бу Регламентның 5.16 пункты нигезендә, Россия Федерациясе яки Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенеңтиешле вәкаләтле органнарына контрольлек чарасын үткәрү объекты булып торган хуҗалык эшчәнлеге яки башка эшчәнлекне хәл итүдә закон таләпләрен бозу турында мәгълүмат (мәгълүматлар) җибәрә;

бу Регламентның 1 нче таблицасындагы 4 пунктында күздә тотылган таләпләрне бозу турында җиңел таксида пассажирлар һәм багаж ташу эшчәнлеген хәл итүгә рөхсәт биргән башка Россия Федерациясе субъектының башка вәкаләтле органына бу Регламентның 5.16 пункты нигезендә мәгълүмат җибәрә;

рөхсәтнең гамәлдә булуын бер айдан артмаган срокка туктатып тора;

судка, бу Регламентның 5.15 пункты нигезендә җиңел таксида пассажир һәм багаж ташу эшчәнлеген хәл итүгә рөхсәтне кире алу (юкка чыгару) турында гариза җибәрә.

Күрсәтмәдә язылган барлык таләпләр тулысынча һәм билгеләнгән срокларда үтәлергә тиеш.

Күрсәтмәнең үтәлешен планнан тыш тикшерү “Юридик затны, индивидуаль эшкуарны документлар аша планнан тыш тикшерү” йә “Юридик затны, индивидуаль эшкуарны урынга барып планнан тыш тикшерү” административ процедураларында билгеләнгән тәртиптә башкарыла.

5.14. Административ хокук бозу турында эшне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча бу регламентның 2.26 пунктында күрсәтелгән вазыйфаи затлар тарафыннан түбәндәге карарларныңберсе чыгарыла:

РФ КоАП 11.14.1 һәм 12.31.1 статьяларында күздә тотылган штрафлар рәвешендә административ җәза билгеләү турында карар, бу Регламентка № 3 кушымтада китерелгән типовой форма нигезендә рәсмиләштерелгән;

Административ хокук бозу турында эш буенча тикшерүне туктату турында карар.

Башкару срогы: административ хокук бозу турында эшне карап тикшерүгә вәкаләтле вазыйфаи затка беркетмә алынганнан соң ун көн эчендә.

Гамәл нәтиҗәсе: административ хокук бозу турында эш буенча административ җәза билгеләү хакында карар яки административ хокук бозу турында эш буенча тикшерүне туктату хакында карар.

5.15. Җаваплы эш башкаручы административ хокук бозу турында эш буенча административ җәза билгеләү хакында карар күчермәсе яки административ хокук бозу турында эш буенча тикшерүне туктату хакында карар күчермәсен, имза салдырып, үзләренә карата карар чыгарылган физик затка яки физик затның законлы вәкиленә, яисә физик затнының законлы вәкиленә тапшыра, шулай ук зыян күрүчегә, үзенеңүтенече буенча, яисә әлеге затларга Министрның документлар әйләнеше бүлеге тарафыннан почта аша заказлы хат белән җибәрелә.

Башкару срогы: административ хокук бозу турында эш буенча административ җәза билгеләү хакында яки административ хокук бозу турында эш буенча тикшерүне туктату хакында карар чыгарылганнан соңөч көн эчендә.

Гамәл нәтиҗәсе: юридик затка яки индивидуаль эшкуаргә административ хокук бозу турында эш буенча административ җәза билгеләү хакында карар күчермәсен яки административ хокук бозу турында эш буенча тикшерүне туктату хакында карар күчермәсен тапшыру яисә җибәрү.

5.16. Төбәк дәүләт контрольлеге чарасы барышында контрольлек чарасын үткәрү объекты булып торучы хуҗалык эшчәнлеге яки башка эшчәнлекнеңМинистрлык компетенциясенә керми торган закон таләпләрен бозуга бәйле булуы ачыкланган очракта, җаваплы эш башкаручы мондый бозулар турында Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте тиешле вәкаләтле органнарына мәгълүмат (мәгълүматлар) җибәрә.

Татарстан Республикасы территориясендә бу Регламентның1 нче таблицасындагы 4 пунктында күздә тотылган бозулар ачыкланганда, җаваплы эш башкаручы тарафыннан әлеге бозу турында җиңел таксида пассажирлар һәм багаж ташу эшчәнлеген хәл итүгә рөхсәт биргән РФ башка субъекты вәкаләтле органына мәгълүмат тапшырыла.

Бозу турында мәгълүмат җибәрү Министрлыкта делопроизводство алып бару кагыйдәләре нигезендә, билгеләнгән тәртиптә теркәлә.

Башкару срогы: төбәк дәүләт контрольлеге чаралары төгәлләнгәннән соңөч эш көне эчендә.

Гамәл нәтиҗәсе:

Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең тиешле вәкаләтле органнарына җибәрелгән бозулар турында мәгълүмат (мәгълүматлар);

җиңел таксидан пассажирлар һәм багаж ташу эшчәнлеген хәл итүгә рөхсәт биргән башка Россия Федерациясе субъектының вәкаләтле органына тапшырылган бозу турында мәгълүмат.

5.17. Күрсәтмәнең үтәлешен раслый торган белешмәләре булган документлар өстәлгән Күрсәтмәне үтәү турында хисап әлеге күрсәтмәдә

билгеләнгән срок тәмамланганчы тапшырылган очракта, җаваплы башкаручы планнан тыш тикшерү үткәрүне бу Регламентның 5.27 – 5.29, 5.31 – 5.39 пунктлары нигезендә әзерли һәм оештыра.

Әлеге күрсәтмәдә билгеләнгән срок чыкканчы күрсәтмәне үтәү турында хисап (күрсәтмәне үтәүне раслаучы мәгълүматлардан торган документлардан гыйбарәт булган) тапшырылмаган очракта яки тапшырылган Хисап әлеге күрсәтмәнең билгеләнгән срокта үтәлүен расламаган очракта җаваплы эш башкаручы бу Регламентның 5.33, 5.34 һәм 5.37, 5.38 пунктлары нигезендә гамәлләр кыла.

5.18. Административ процедура төгәлләнгәннән соң җаваплы эш башкаручы Министрлыкның мәгълүматлаштыру һәм мәгълүмат бүлегенә, планлы документар тикшерүне үтәү нәтиҗәсен теркәү максатыннан чыгып, Министрлыкның рәсми сайтында тиешле мәгълүмат урнаштыру турында хезмәт язуы җибәрә.

Башкару срогы: мәгълүматны урнаштыру – административ процедура төгәлләнгәннән соң өч эш көне эчендә.

Гамәл нәтиҗәсе: Министрлыкның рәсми сайтына планлы документар тикшерү үткәрү нәтиҗәләре турында мәгълүмат урнаштыру.

## “ЮРИДИК ЗАТКА, ИНДИВИДУАЛЬ ЭШКУАРГӘ ПЛАНЛЫ КҮЧМӘ ТИКШЕРҮ ҮТКӘРҮ” АДМИНИСТРАТИВ ПРОЦЕДУРАСЫ

5.19. Административ процедурасын башлауга нигез булып, тиешле юридик затны, индивидуаль эшкуарне еллык Планга кертү тора, шулай ук документар тикшерү вакытында түбәндәгеләргә ирешеп булмау тора:

1) Министрлык карамагындагы юридик зат, индивидуаль эшкуар документларындагы мәгълүматларныңтулылыгы һәм дөреслегенә ышанып булмау;

2) тиешле контрольлек чарасын үткәрмичә генә юридик зат, индивидуаль эшкуар эшчәнлегененңмәҗбүри таләпләргә туры килүен бәяләп булмау.

Юридик затка, индивидуаль эшкуаргә планлы күчмә тикшерү үткәрүне еллык Планга кертү бу Регламентның 2.14 пунктында күрсәтелгән нигезләр буенча хәл ителә.

Административ процедура бу Регламентның 5.5 пунктында күрсәтелгән административ гамәлләр тәртибе нигезендә хәл ителә.

Күчмә тикшерү предметы булып юридик зат, индивидуаль эшкуар документларындагы мәгълүматлар, шулай ук хезмәткәрләренең, эшчәнлекне хәл итүдә әлеге затлар тарафыннан файдаланыла торган җиһазларның, транспорт чараларының, үтәлгән эшнең мәҗбүри таләпләргә туры килүе һәм алар тарафыннан мәҗбүри таләпләрне үтәү чаралары тора.

5.20. Җаваплы эш башкаручыны билгеләү, планлы күчмә тикшерү үткәрү

турында боерык әзерләү, планлы күчмә тикшерү үткәрү турында юридик затка, индивидуаль эшкуаргә уведомление җиткерү бу Регламентның 5.6. – 5.8 пунктлары нигезендә хәл ителә.

5.21. Җаваплы эш башкаручы, экспертлар, эксперт оешмалары вәкилләре юридик зат, индивидуаль эшкуар объектына килгәннән соңтикшеренү башлый:

хезмәт таныклыкларын күрсәтүдән;

юридик зат җитәкчесен яки башка вазыйфаи затын, индивидуаль эшкуарне, индивидуаль эшкуарның вәкаләтле вәкилен планлы күчмә тикшерү билгеләү турында министр (министр урынбасары) боерыгы белән таныштырудан;

юридик зат җитәкчесен яки башка вазыйфаи затын, индивидуаль эшкуарне планлы күчмә тикшерү үткәрүче затларның вәкаләтләре, шулай ук планлы күчмә тикшерү үткәрү максатлары, бурычлары, нигезләре, контрольле чарлары төрләре һәм күләмнәре, планлы күчмә тикшерүгә җәлеп ителә торган экспертлар составы, эксперт оешмалары вәкилләре, аны үткәрү сроклары һәм шартлары белән мәҗбүри таныштырудан.

Җаваплы эш башкаручы, экспертлар, эксперт оешмалары вәкилләре юридик зат, индивидуаль эшкуар эшчәнлегенеңбу регламентның 3 бүлегендә китерелгән мәҗбүри таләпләргә туры килүен бәяли.

Башкару срогы: бу Регламентның 2.9-2.10 пунктлары нигезендә.

Гамәл нәтиҗәсе: юридик зат, индивидуаль эшкуар эшчәнлегенеңбу Регламентның 3 бүлегендә күздә тотылган мәҗбүри таләпләргә туры килүен бәяләү максатыннан чыгып, төбәк дәүләт контрольлеге буенча чаралар үткәрү.

5.22.Җаваплы эш башкаручы, үткәрелгән төбәк дәүләт контрольлеге чаралары нигезендә, ике нөсхәдә тикшерү акты төзи. Тикшерү актын төзү һәм юридик затны, индивидуаль эшкуарне тикшерү акты (кушымталар белән, шул исәптән күрсәтмә белән), беркетмә (аны рәсмиләштерү зарурилыгы булганда) белән таныштыру бу Регламентның 5.11, 5.12 пунктлары нигезендә хәл ителә.

Тикшерү актына кушып бирелә:

күрсәтмә;

үзләренә мәҗбүри таләпләрне бозган өчен җаваплылык йөкләнгән юридик зат хезмәткәрләре, индивидуаль эшкуар аңлатмалары;

тикшерү нәтиҗәләре белән бәйле башка документлар яки аларныңкүчермәләре.

Тикшерү актын төзү өчен үткәрелгән тикшеренүләр, сынаулар, махсус тикшерүләр, экспертизалар нәтиҗәләре буенча бәяләмә алырга кирәк булган очракта, җаваплы эш башкаручы тикшерү актын юридик затка, индивидуаль эшкуаргә контрольлек чаралары тәгәлләнгәннән соңөч эш көненнән артмаган срокта җибәрә.

Тикшерү актын төзү өчен үткәрелгән өйрәнүләр, сынаулар, махсус тикшерүләр, экспертизалар нәтиҗәләре турында бәяләмә алырга кирәк булган

очракта, җаваплы башкаручы контроль чаралар тәмамланганнан соң иң күбе өч эш көне эчендә актны расписка йә тапшырылуы турында хәбәр ителә торган хат белән почта аша һәм (яисә) мондый актны төзегән затның (җаваплы башкаручының) ныгытылган квалификацияле электрон имзасы куелган электрон документ рәвешендә әлеге документны алуны раслый торган ысул белән юридик зат җитәкчесенә, башка вазыйфаи затына яисә вәкаләтле вәкиленә, индивидуаль эшкуарга, аның вәкаләтле вәкиленә җибәрә. Мондый документны тапшыру турында хәбәрнамә һәм (яисә) аны алуны раслый торган башка документ тикшерү актының Министрлыкта саклана торган нөсхәсенә өстәп куела.

Индивидуаль эшкуар, аның вәкаләтле вәкиле, юридик зат җитәкчесе яисә башка вазыйфаи заты булмау сәбәпле урынга барып планлаштырылган яисә планнан тыш тикшерү үткәрү мөмкин булмаган очракта йә индивидуаль эшкуар, юридик зат фактта эшчәнлекне гамәлгә ашырмаса яки индивидуаль эшкуарның, аның вәкаләтле вәкиленең, юридик зат җитәкчесенең яисә башка вазыйфаи затының гамәлләре (гамәл кылмавы) аркасында тикшерү үткәрү мөмкинлеге булмаса, Министрлыкның вазыйфаи заты, тикшерүне үткәрә алмау сәбәпләрен күрсәтеп, тиешле тикшерү үткәрүнең мөмкин булмавы турында акт төзи. Бу очракта тиешле тикшерү үткәрүнең мөмкин булмавы турында акт төзелгән көннән алып өч ай эчендә Министрлык мондый юридик затны, индивидуаль эшкуарны урынга барып планлаштырылган яисә планнан тыш тикшерү турында карар кабул итә ала, мондый тикшерү еллык тикшерүләр планына кертелми һәм юридик затка, индивидуаль эшкуарга алдан хәбәр ителмәскә дә мөмкин.

5.23. Юридик зат, индивидуаль эшкуар 141 номерлы Россия Икътисадый үсеш министрлыгы боерыгы белән расланган типовой формада алып барган очракта җаваплы эш башкаручы юридик затның, индивидуаль эшкуарның тикшерүләр учеты журналында Министрлыкның атамасы, тикшерүнең башлану һәм тәмамлану даталары, аны үткәрү вакыты, тикшерүнең хокукый нигезләре, максатлары, бурычлары һәм предметы, ачыкланган бозулар һәм бирелгән күрсәтмәләр турында мәгълүматлардан торган, шулай ук тикшерү үткәрүче затларның фамилияләре, исемнәре, атасыныңисемнәре һәм вазыйфалары, аларның имзалары күрсәтелгән үткәрелгән планлы күчмә тикшерү турында язып куя.

Башкару срогы: турыдан-туры тикшерү тәмамланганнан соң.

Гамәл нәтиҗәсе: юридик затны, индивидуаль эшкуарне тикшерүләр учеты журналына үткәрелгән планлы күчмә тикшерү турында язып кую.

5.24. Планлы күчмә тикшерү нәтиҗәләре буенча закон нигезендә күздә тотылган чаралар күрү бу Регламентның 5.13 пункты нигезендә хәл ителә.

5.25. Күрсәтмәне үтәү турында хисап (күрсәтмәне әлеге күрсәтмәдә билгеләнгән срок чыкканчы үтәүне раслаучы мәгълүматлардан торган

документларны үз эченә алган) тапшырмаган очракта яки тапшырылган Хисап әлеге күрсәтмәнең билгеләнгән срокта үтәлүен расламаган очракта, җаваплы эш башкаручы бу Регламентның 5.33, 5.34 һәм 5.37, 5.38 пунктлары нигезендә гамәлләр кыла.

5.26. Административ процедура төгәлләнгәннән соңҗаваплы эш башкаручы Министрлыкның Мәгълүматлаштыру һәм мәгълүмат бүлегенә, планлы күчмә тикшерүне үтәү нәтиҗәсен теркәү максатыннан чыгып, Министрлыкның рәсми сайтына тиешле мәгълүмат урнаштыру турында хезмәт язуын җибәрә.

Башкару срогы: мәгълүмат урнаштыру – административ процедура төгәлләнгәннән соң өч эш көне эчендә.

Гамәл нәтиҗәсе: Министрлыкның рәсми сайтына планлы күчмә тикшерү үткәрү нәтиҗәләре турында мәгълүмат урнаштыру.

## ЮРИДИК ЗАТКА, ИНДИВИДУАЛЬ ЭШКУАРГӘ ПЛАННАН ТЫШ ДОКУМЕНТАР ТИКШЕРҮ ҮТКӘРҮ” АДМИНИСТРАТИВ ПРОЦЕДУРАСЫ

5.27. Административ процедураны башлауга нигез булып бу Регламентның 2.16 пунктында күрсәтелгән очраклар тора.

Административ процедура түбәндәге административ гамәлләр тәртибендә хәл ителә:

тикшерү үткәрүгә җаваплы вазыйфаи затларны билгеләү;

тикшерү үткәрү турында боерык рәсмиләштерү;

тикшерү үткәрү;

тикшерү йомгаклары буенча тикшерү акты, башка документлар әзерләү;

юридик затны, индивидуаль эшкуарне тикшерү акты белән таныштыру;

тикшерү нәтиҗәләре буенча законда күздә тотылган чаралар күрү.

Планнан тыш тикшерү предметы юридик зат, индивидуаль эшкуар эшчәнлеге процессында мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен, Министрлык күрсәтмәләре үтәлешен, гражданнар гомеренә һәм сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарих һәм мәдәният ядкарьләренә) зарар салуны булдырмау, дәүләтнең иминлеген тәэмин итү, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгуны кисәтү, мондый хәлләр аркасында килеп чыккан зарарларны бетерү чараларын үткәрүне тикшерүдән гыйбарәт.

5.28. Министр (министр урынбасары) бу Регламентның 2.16 пунктында күрсәтелгән планнан тыш документар тикшерү үткәрүгә нигезләр килеп чыкканда, Бүлек начальнигына планнан тыш документар тикшерүне оештыру һәм үткәрү турында поручение бирә.

Бүлек начальнигы җаваплы эш башкаручылар, кирәк булганда, юридик

затка, индивидуаль эшкуаргә планнан тыш документар тикшерү үткәрү өчен экспертлар билгели.

Башкару срогы: планнан тыш документар тикшерү үткәрүгә нигезләр килеп чыкканнан соңбер көн эчендә.

Гамәл нәтиҗәсе:

планнан тыш документар тикшерү оештыру һәм үткәрү турында министр тарафыннан поручение бирелү, планнан тыш документар тикшерү үткәрү өчен җаваплы эш бирүчеләрне билгеләү.

5.29. Планнан тыш документар тикшерү үткәрү турында министр (министр урынбасары) боерыгын әзерләү, планнан тыш документар тикшерү үткәрү өчен җаваплы эш башкаручыларны билгеләү көнендә, бу Регламентның 5.7 пункты нигезендә хәл ителә.

5.30. Тикшерү үткәргәндә җаваплы эш башкаручыныңюридик зат, индивидуаль эшкуар документларындагы мәгълүматларны бәяләү, хат (нигезле запрос) әзерләү, юридик зат, индивидуаль эшкуар документларын һәм (яки) аңлатмаларын карап тикшерү буенча гамәлләре бу Регламентның 5.9, 5.10 пунктлары нигезендә хәл ителә.

5.31. Тикшерү актын төзү һәм юридик затны, индивидуаль эшкуарне тикшерү акты (кушымталары белән, шул исәптән күрсәтмә белән), беркетмә (рәсмиләштерү кирәк булганда) белән таныштыру бу Регламентның 5.11, 5.12 пунктлары нигезендә хәл ителә.

Тикшерү актына яңа ачыкланган бозулар, шулай ук системалы төс алган бозулар фактлары мәҗбүри тәртиптә теркәлә.

5.32. Планнан тыш документар тикшерү үткәрү нәтиҗәләре буенча законда күздә тотылган чаралар күрү бу Регламентның 5.13 пункты нигезендә хәл ителә.

5.33. Бирелгән күрсәтмә үтәлмәгән очракта (шул исәптән Министрлыкка әлеге күрсәтмәдә билгеләнгән срок чыкканчы Хисап тапшырылмаган яки тапшырылган Хисап әлеге күрсәтмәнеңбилгеләнгән срокта үтәлүен расламаган очракта) җаваплы эш башкаручы юридик затка, индивидуаль эшкуаргә, рөхсәтнеңгамәлдә булуын туктатып тору турында уведомление белән, рөхсәтнеңгамәлдә булуын туктатып тору сәбәпләрен күрсәтеп, Министрлык боерыгы проектын һәм хат проектын әзерли һәм аларны министрга (министр урынбасары) имза салуга җибәрә, ул бер айдан артмаган срокка рөхсәтнеңгамәлдә булуын туктатып тору турында карар кабул итә.

Башкару срогы:

боерык проекты – Министрлык күрсәтмәсен үтәү срогы чыкканнан соңкиләсе эш көне дәвамында;

рөхсәтнең гамәлдә булуын туктатып тору турында уведомление белән, юридик затка, индивидуаль эшкуаргә җибәрелгән хат – карар кабул ителгәннән соңөч көч эчендә.

Гамәл нәтиҗәсе: рөхсәтнең гамәлдә булуын туктатып тору турында уведомление белән, юридик затка, индивидуаль эшкуаргә җибәрелгән боерык проекты, хат.

5.34. Җаваплы эш башкаручы бирелгән рөхсәтләр реестрына тиешле язу кертә.

Рөхсәтнеңгамәлдә булу срогы аныңгамәлдә булуын туктатып тору вакытына озайтылмый.

Башкару срогы: рөхсәтнең гамәлдә булуын туктатып тору турында карар кабул ителгәннән соң өч көн эчендә.

Гамәл нәтиҗәсе: бирелгән рөхсәтләр реестрына рөхсәтнеңстатусын үзгәртү турында язып кую.

5.35. Юридик зат яки индивидуаль эшкуар рөхсәтнеңгамәлдә булуын туктатып тору срогы чыкканчы Министрлыкка күрсәтмәнең(аны үтәмәү рөхсәтнеңгамәлдә булуын туктатып торуга китергән) үтәлүен раслаучы мәгълүматлар тапшырган очракта, җаваплы эш башкаручы Министрлыкныңбоерык проектын һәм юридик затка, индивидуаль эшкуаргә, рөхсәтнеңгамәлдә булуын яңарту турында уведомление белән, хат проекты әзерли һәм аларны министрга (министр урынбасары ) имза салуга җибәрә.

Башкару срогы: документлар тапшырылганнан соңбиш эш көне эчендә.

Гамәл нәтиҗәсе: боерык проекты әзерләү, юридик затка, индивидуаль эшкуаргә, рөхсәтнеңгамәлдә булуын яңарту турында уведомление белән хат җибәрү.

5.36. Җаваплы эш башкаручы бирелгән рөхсәтләр реестрына рөхсәтнеңгамәлдә булуын яңарту турында үзгәреш кертә.

Башкару срогы: рөхсәтнеңгамәлдә булуын яңарту турында карар кабул ителгәннән соң өч көн эчендә.

Гамәл нәтиҗәсе: бирелгән рөхсәтләр реестрына рөхсәтнеңгамәлдә булуын яңарту турында язып кую.

5.37. Юридик зат яки индивидуаль эшкуар күрсәтмәнең(аны үтәмәү рөхсәтнеңгамәлдә булуын туктатып торуга китергән) үтәлүен раслаучы мәгълүматлардан торган документларны (Хисап) рөхсәтнеңгамәлдә булуын туктатып тору срогы чыкканчы Министрлыкка тапшырмаган очракта яисә тапшырылган документлар (Хисап) күрсәтмәнең(аны үтәмәү рөхсәтнеңгамәлдә булуын туктатып торуга китергән) үтәлүен расламаган очракта, җаваплы эш башкаручы:

рөхсәтне кире алу (юкка чыгару) турында судка гариза проекты әзерли;

аны министрга (министр урынбасары) имза салуга җибәрә;

имза салынганнан соңгаризаны, теркәүгә алу һәм судка җибәрү өчен, Министрлыкныңдокументлар әйләнеше бүлегенә җибәрә.

Рөхсәтнеңгамәлдә булуын туктатып тору суд карары законлы көченә кергәнче озайтыла.

Рөхсәтне кире алу (юкка чыгару) турында судка гариза түбәндәге очракларда җибәрелә:

1) рөхсәтнең гамәлдә булу срогы дәвамында бу Регламентның 1 нче таблицасындагы 4 пунктында күздә тотылган таләпләр кабат бозылганда, яки бу Регламентның 3 бүлегендәге 1 нче таблицаның 1.1-1.4 пунктчаларында күздә тотылган таләпләр кабат үтәлмәгәндә;

2) рөхсәтнең гамәлдә булуын туктатып тору срогы дәвамында бу Регламентның 5.11 пунктында күрсәтелгән күрсәтмә үтәлмәгәндә яки әлеге срок чыкканчы тапшырылган күрсәтмәне үтәү турында Хисап күрсәтмәненүтәлүен расламаганда;

3) бу Регламентның 1 нче таблицасында 2 пунктында күздә тотылган таләпләрне бозулар ачыкланганда;

4) җиңел такси йөртүченеңпассажир яки өченче затлар үлеменә яисә сәламәтлегенә авыр яки уртача авырлыкта зыян салуга китергән юл-транспорт һәлакәте кылганда.

Башкару срогы: рөхсәтнеңгамәлдә булуын туктатып тору срогы чыкканнан соңбиш эш көне эчендә.

Гамәл нәтиҗәсе: рөхсәтне кире алу, юкка чыгару турында судка гариза җибәрү.

5.38. Җаваплы эш башкаручы суд тарафыннан рөхсәтне кире алу (юкка чыгару ) турында карар кабул ителгәннән соңбирелгән рөхсәтләр реестрына тиешле язу кертә.

Башкару срогы: суд тарафыннан карар кабул ителгәннән соң өч көн эчендә.

Гамәл нәтиҗәсе: бирелгән рөхсәтләр реестрына рөхсәтне кире алу (юкка чыгару) турында тиешле язу кертү.

5.39. Җаваплы эш башкаручы административ процедура төгәлләнгәннән соң, планнан тыш документар тикшерү башкару нәтиҗәсен теркәү максатыннан чыгып, Министрлыкныңрәсми сайтына тиешле мәгълүмат урнаштыру турында Министрлыкныңмәгълүматлаштыру һәм мәгълүмат бүлегенә хезмәт язуы җибәрә.

Башкару срогы: мәгълүмат урнаштыру – административ процедура төгәлләнгәннән соң өч эш көне эчендә.

Гамәл нәтиҗәсе: Министрлыкныңрәсми сайтына планнан тыш документар тикшерү нәтиҗәләре турында мәгълүмат урнаштыру.

## "ЮРИДИК ЗАТКА, ИНДИВИДУАЛЬ ЭШКУАРГӘ ПЛАННАН ТЫШ КҮЧМӘ ТИКШЕРҮ ҮТКӘРҮ" АДМИНИСТРАТИВ ПРОЦЕДУРАСЫ

5.40. Административ процедураны башлауга нигез булып бу Регламентының 2.16 пунктында күрсәтелгән очраклар тора, шулай ук

документар тикшерү вакытында түбәндәгеләргә ирешү мөмкин булмаганда:

1) Минитсрлык карамагындагы юридик зат, индивидуаль эшкуар документларында мәгълүматларныңтулылыгы һәм дөреслегенә инану;

2) тиешле контрольлек чарасын үткәрмичә генә юридик зат, индивидуаль эшкуар эшчәнлегенеңмәҗбүри таләпләргә туры килүен бәяләү.

Административ процедура бу Регламентның 5.5 пунктында күрсәтелгән административ гамәлләр тәртибендә хәл ителә.

5.41. Юридик затка, индивидуаль эшкуаргә планлы күчмә тикшерү үткәрү өчен җаваплы эш башкаручыны, экспертлар билгеләү бу Регламентның 5.28 пункты нигезендә хәл ителә.

5.42. Планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү турында министр (министр урынбасары) боерыгын әзерләү бу Регламентның 5.7 пункты нигезендә хәл ителә.

Башкару срогы: планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү өчен җаваплы эш башкаручыны билгеләү көнендә.

Гамәл нәтиҗәсе: планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү турында министр (министр урынбасары) имзалаган боерык.

5.43. Планнан тыш күчмә тикшерү үткәрүгә нигез булып бу Регламентның 2.16 пунктындагы 2 пунктчасында күрсәтелгән нигез торган очракта, җаваплы эш башкаручы:

юридик зат, индивидуаль эшкуар эшчәнлеген хәл итү урыны буенча прокуратура органына планнан тыш күчмә тикшерү үткәрүне килештерү турында гариза әзерли, гаризага министрдан (министр урынбасары) имза салдыра (планнан тыш күчмә тикшерү үткәрүне прокуратура органы белән килештерү турында гаризаныңтиповой формасы Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 141 номерлы боерыгы белән расланган);

Министрлыкныңдокументлар әйләнеше бүлегенә, теркәүгә алу һәм прокуратура органыннан кулдан тапшыру, почта аша заказлы хат белән (тапшыру турында уведомление белән) яки электрон санлы имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә юллау өчен, гариза җибәрә. Гаризага планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү турында министр (министр урынбасары) боерыгы һәм аны үткәрүгә нигез булып хезмәт иткән мәгълүматлардан торган документлар кушып бирелә.

Башкару срогы: планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү турында боерык имзаланганнан соң 24 сәгать эчендә.

Гамәл нәтиҗәсе: планнан тыш күчмә тикшерү үткәрүне килештерү турында гаризаны прокуратура органына җибәрү.

5.44. Җаваплы эш башкаручы юридик затка, индивидуаль эшкуаргә планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү турында, тикшерү башланырга кимендә егерме дүрт сәгать кала, теге яки бу уңайлы ысул белән хәбәр җиткерә (бу Регламентның 2.16 пунктындагы 2 пунктчасында күрсәтелгән нигезләр планнан

тыш күчмә тикшерү үткәрүгә нигез булып торган очраклардан тыш), шул исәптән ныгытылган квалификацияле электрон имза куелган һәм юридик затның, индивидуаль эшкуарның электрон адресына җибәрелгән, әгәр мондый адрес юридик затларның бердәм дәүләт реестрында, индивидуаль эшкуарларның бердәм дәүләт реестрында булса, Министрлыкка юридик зат, индивидуаль эшкуар тарафыннан элегрәк бирелгән булса электрон документ рәвешендә җаваплы башкаручы тарафыннан җибәреп хәбәр ителә.

Планнан тыш күчмә тикшерү үткәрүгә бу Регламентның 2.16 пунктындагы 2 пунктчасында күрсәтелгән нигез торган очракта, кичекмәстән чаралар күрү зарурилыгына бәйле рәвештә, Министрлык, индивидуаль эшкуаргә яки юридик затка уведомление җиткермичә генә, прокуратура органнарына кичекмәстән хәбәр итеп, планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү турында үткәрүгә керешүгә хокуклы.

Башкару срогы: тикшерүне башлауга кимендә егерме дүрт сәгать кала.

Гамәл нәтиҗәсе: планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү турында юридик затка, индивидуаль эшкуаргә уведомление җибәрү.

5.45. Планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү бу Регламентның 5.21 пункты нигезендә хәл ителә

5.46. Тикшерү акты төзү һәм юридик затны, индивидуаль эшкуарне тикшерү акты (кушымталары белән, шул исәптән күрсәтмә белән), беркетмә (рәсмиләштерү кирәк булганда) белән таныштыру, шулай ук индивидуаль эшкуарның, аның вәкаләтле вәкиленең, юридик зат җитәкчесенең яисә башка вазыйфаи затының тикшерүне үткәрә алмауга китергән гамәлләре (гамәл кылмавы) аркасында тикшерү үткәрү мөмкин булмавы турында акт төзү бу Регламентның 5.22 пункты нигезендә хәл ителә

5.47. Планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү прокуратура органы белән килештереп хәл ителгән очракта, җаваплы эш башкаручы прокуратура органына тикшерү акты күчермәсен җибәрә.

Башкару срогы: тикшерү акты төзелгәннән соңбиш эш көне эчендә.

Нәтиҗә: тикшерү акты күчермәсен прокуратура органына җибәрү.

5.48.Тикшерү нәтиҗәләре буенча ачыклау, кисәтү һәм киртә кую Министрлык компетенциясенә кермәгән закон таләпләрен яки бу Регламентның 1 нче таблицасындагы 4 пунктында күздә тотылган таләпләрне бозулар ачыкланганда яки бирелгән күрсәтмәнеңүтәлмәү очрагында законда күздә тотылган чаралар күрү максатыннан чыгып, җаваплы эш башкаручы бу Регламентның 5.15 -5.17 пункты нигезендә гамәлләр кыла.

5.49. Планнан тыш күчмә тикшерү нәтиҗәләре буенча законда күздә тотылган чаралар күрү бу Регламентның 5.13 пункты нигезендә хәл ителә.

5.50. Административ процедура тәгәлләнгәннән соңҗаваплы эш башкаручы, планнан тыш күчмә тикшерүне башкару нәтиҗәсен теркәү максатыннан чыгып, Министрлыкныңрәсми сайтына тиешле мәгълүмат

урнаштыру турында Министрлыкныңмәгълүматлаштыру һәм мәгълүмат бүлегенә хезмәт язуы җибәрә.

Башкару срогы: мәгълүматны урнаштыру – административ процедура төгәлләнгәннән соң өч эш көне эчендә.

Гамәл нәтиҗәсе: Министрлыкныңрәсми сайтына планнан тыш күчмә тикшерүне башкару нәтиҗәләре турында мәгълүмат урнаштыру.

## ДӘҮЛӘТ ВАЗЫЙФАСЫН ҮТӘҮГӘ КОНТРОЛЬЛЕК ИТҮ ТӘРТИБЕ ҺӘМ ФОРМАЛАРЫ

6.1. Министрлык вазыйфаи затлар тарафыннан хезмәт бурычларын үтәүләренә контрольлекне хәл итә, тикшерүләр үткәрү барышында вазыйфаи затларныңүз вәкаләтләрен тиешенчә үтәмәү очраклары учетын алып бара, тиешле хезмәт тикшеренүләре үткәрә һәм мондый вазыйфаи затларга карата Россия Федерациясе законы нигезендә чаралар күрә.

6.2. Бу Регламентныңүтәлүенә контрольлек итү министр тарафыннан хәл ителә.

6.3. Министрлыкныңдәүләт вазыйфасын үтәүгә җаваплы вазыйфаи затларыныңбу Регламент һәм дәүләт вазыйфасын үтәүгә карата таләпләр билгеләүче башка норматив-хокукый актлар нигезләмәләрен үтәүгә, шулай ук алар тарафыннан карарлар кабул ителүгә агымдагы контрольлекне министр урынбасары, дәүләт вазыйфасын үтәүгә компетентлы Министрлык идарәсе җитәкчесе һәм Министрлыкныңвәкаләтле хезмәткәрләре хәл итә.

6.4. Министрлыкныңдәүләт вазыйфасын үтәүгә агымдагы контрольлекне хәл итүгә вәкаләтле  хезмәткәрләренеңисемлеге, әлеге контрольлекне хәл итүнеңтәртибе һәм вакыт аралыклары Министрлык актлары нигезендә билгеләнә.

